*Ий, мөэминнәр! Барчаларыгыз да бирелгән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә нык тотынып ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!* (Коръәни-Кәрим, 3:103.)

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

6+

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ • № 4 (225) АПРЕЛЬ 2014 / ҖӨМӘДИӘЛАХЫР 1435

## БҮГЕНГЕ САНДА:

## УРТАК МАКСАТЫБЫЗ – ДИННЕ КҮТӘРҮ



9 нчы бит

## ИЛАҺИ МОҢНЫ САКЛАРГА ЯЗСЫН





8 нче бит

## “МӨСЕЛМАН ЫШАНЫЧ ТЕЛЕФОНЫ” ТЫҢЛЫЙ

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм Россия мөселман яшьләре берлеге “Мөселман ышаныч телефоны” дип аталган яңа проект эшләтеп җибәрде. **(843) 202-4-202** телефон номерын җыеп, белгечләргә исламга кагылышлы сорауларны бирергә мөмкин.

Әлеге проектның максаты - социаль киеренкелекне киметү, халыкка ислам турында дөрес мәгълүмат җиткерү, традицион дини кыйммәтләрне пропагандалау һәм мигрантларга безнең җирлеккә яраклашырга ярдәм итү.

Проект кысаларында өч белгеч - шәригать буенча эксперт, мөселман психологы һәм юрист эшләячәк. Белгечләр шалтыратучыларга рус һәм татар телләрендә җавап бирә. Алга таба, таҗик һәм үзбәк телләрендә җавап бирерлек белгечләрне җәлеп итү күздә тотыла.

“Мөселман ышаныч телефоны” бары тик мөселманнар өчен генә эшли икән, дип нәтиҗә ясарга ашыкмагыз. Ислам диненә, мөселманнарга кагылышлы сораулары булган һәркем әлеге телефон буенча шалтырата ала. Озакламый сорауларны махсус социаль челтәр чыганаклары аша да биреп булачак.



**СӨЕМБИКӘ ЭНЕЛӘРЕ ҺӘМ СЕҢЕЛЛӘРЕ СЫНАТМАДЫ**

10 нчы бит



**ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗ (С.Г.В.) ХАҖНЫ ЯШЬ ЧАКТА КЫЛЫРГА КУШКАН**

11 нче бит



**ИСЕМЕҢ МАТУР, КЕМНӘР КУЙГАН?**

14 нче бит

ГАЗЕТАДА АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ ИСЕМНӘРЕ, КОРЪӘННӘН АЯТЬЛӘР БАР, АНЫ ТИЕШСЕЗ УРЫНГА КУЛЛАНУДАН САКЛАНЫГЫЗ!

## Россия мөселман яшьләре берлегенең Мәскәү бүлеге ачылды

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Мәскәүгә эшлекле сәфәре кысаларында Россия мөселман яшьләре берлегенең Мәскәүдә бүлеге ачылу тантанасында катнашты. Яңа бүлекне Мәскәү яшьләре активисты Рәмис Якупов җитәкләячәк.

Россия мөселман яшьләре берлеге җитәкчесе Марсель Сабиров Рәмис Якупов белән хезмәттәшлек турында сөйләште һәм төрле өлкәләргә кагылышлы эш планнарын билгеләде. Бүлек мөселман яшьләренең белемен күтәрү, төрле конференцияләр уздыру һәм берлеккә мөселманнарны җәлеп итеп, бердәм булып өммәтебезгә хезмәт итүне оештыру белән шөгыльләнәчәк дип көтелә.

Тантанада шулай ук Мәскәү һәм Үзәк төбәк Диния нәзарәте рәисе мөфти Әлбир хәзрәт Крганов, мөселман яшьләре катнашты.

## Малайзия журналистлары Татарстанда

Малайзия дәүләт телерадиокомпаниясе журналистлары Татарстанда татарларның рухи тормышы хакында документаль фильм төшерә. Алар Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин белән очраштылар. Камил хәзрәт чит ил журналистларына татарлар арасында ислам таралу, республиканың бүгенге мөселман өммәте, ТР МДН эшчәнлеге хакында сөйләде.

Малайзия дәүләт телерадиокомпаниясе продюсерлары Мохд Фирдәүс һәм Ризван Мохтар әйтүенә караганда, Татарстан мөселманнары турындагы тапшырулар рамазан ае дәвамында күрсәтеләчәк.

Ике атна дәвамында чит ил журналистлары Россия ислам институтында, Ярдәм мәчетендәге күрмәүчеләрне укыту-тернәкләндерү үзәгендә, "Хузур" нәшрият йортында һәм башка мөселман оешмаларында булдылар.

## Казанга азан әйтүчеләр җыела

Апрель азагында Казан шәһәре мөхтәсибәте Әл-Мәрҗани мәчете белән берлектә шәкертләр, дини югары белем бирү уку йортлары студентлары, мөәзиннәр арасында Азан әйтүчеләрнең Бөтенроссия конкурсын уздыра. Анда 3 төркемдә: 10 яшьтән 15 яшькәчә, 15 яшьтән 20 яшькәчә һәм 20 яшьтән өлкән шәкертләр, мөәзиннәр катнаша ала. "Чараның максаты - яшь мөселманнарны Әбу Ханифә мәзһәбе нигезендә тәрбияләү, шәкертләрне һәм мөәзиннәрне намазга чакыру догасын дөрес, сәнгатьле итеп көндәлән укырга өйрәтү. Аны мөселманнар мәчеткә ашыгырлык итеп әйтергә тиешләр", - дип хәбәр итә Әл-Мәрҗани мәчете матбугат хезмәте.

***Конкурска гаризалар marjani-mechet@mail.ru электрон адресына, (843) 93-00-35 яки 89272495632 һәм 89172644321 телефоннары аша кабул ителә.***

# ТӨРКИ ДӨНЬЯ ТАТАР ТӘГЪЛИМАТЧЫЛАРЫН ӨЙРӘНӘ

**Казан федераль университетында "Татар җәдитчелеге феномены: Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэддин Фәхретдин, Муса Бигиев" дип аталган халыкара фәнни семинар узды.**

Мәгълүм булганча, XIX гасырда Идел буе мөселманнары арасында җәдитчелек дип аталган иҗтимагый-сәяси һәм интеллектуаль хәрәкәт киң таралыш ала. Җәдитчелек тарафдарлары, алгарыш хакына эшләүне үзләренең бурычлары санап, тәрбия һәм мәгърифәтчелек аша муллаларга, гади мөселманнарга цивилизациянең өстенлекләрен күрсәтергә тырышкан. Алар бигрәк тә төрки халыкларның телләрен һәм әдәбиятын үстерү, дөньяви фәннәрне өйрәнү, фән казанышларын файдалану яклы булганнар.

"Казан – төрки дөньяның 2014 нче елгы мәдәни башкаласы" программасы кысаларында уздырылучы әлеге семинар эшендә татарның бөек ислам тәгълиматчылары мирасын өйрәнүче 70 тән артык Россия һәм Төркия галиме катнашты. Ике көн дәвамында барган бу форумда Россия - Төркия бәйләнешлары тарихы, төрки мәдәният, төрки-мөселман җәмгыятендәге яңарыш процессларында мәшһүр татар иҗтимагый һәм дин эшлеклеләренең роле турында чыгышлар ясалды. Җәдитчелек идеологларының хәзерге тормышыбызга йогынтысы; Татарстан белән Төркиянең, Казан федераль университетының төрек вузлары белән хезмәттәшлеге турындагы мәсьәләләр күтәрелде.

Шундый ук чара берничә атна элек Төркиянең Иске шәһәрендә дә оештырылган иде. Анда Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте вәкилләре дә катнашты.

***

Әлеге семинарда катнашу өчен килгән Төркиянең Каллиграфия институты җитәкчесе Хосрәү Субаш, Истанбул һәм Әнкара университетының теология факультеты җитәкчеләре Али Арслан һәм Ибраһим Мараш, мәдәни платформа җитәкчесе Мәхмүт Камил һәм Төркиянең башка галимнәре Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә дә булып киттеләр. Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин кунаклар белән танышкач, аларга татар халкының дини рухи мирасы һәм бу мирасны торгызу ниятеннән кылынган гамәлләр хакында сөйләде. Бүгенге көндә күренекле татар дин белгечләренең дистәләгән китаплары өйрәнелә һәм иске татар теленнән хәзерге телгә күчерелеп нәшер ителә. Билгеле булганча, нәзарәт көче белән рухи мирасыбыз ядкярләре булган берничә китап дөнья күрде инде.

Фәнни эшчәнлекләрен югары бәяләп, мөфти хәзрәт Төркия галимнәренә рәхмәт сүзләрен җиткерде. Аларның татар галимнәренең хезмәтләрен өйрәнүләре бар татар халкы өчен мөһим булуын ассызыклады.

# ТАТАРСТАН МӨФТИЕ «ГАЗПРОМ ТӨБӘКАРАГАЗ КАЗАН» ОЕШМАСЫ ҖИТӘКЧЕСЕ БЕЛӘН ОЧРАШТЫ

**Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин "Газпром төбәкарагаз Казан" оешмасы генераль директоры, ТР Дәүләт Советы депутаты Ринат Ханбиков белән очрашты.**



Рәсми очрашуда сүз авыл җирлегендә эшләүче дини оешмаларның, мәчетләрнең газга түләүләренә чыгымнарны киметү хакында барды.

ТР МДН җыелышларында, мөфти белән очрашуларда имамнар мәчетләрне җылытуга кагылышлы чыгымнар проблемасын даими күтәреп киләләр. Шуны әйтергә кирәк, бүгенге көндә дини оешмаларның газга түләүләре юридик затларныкы кебек зур күләмдә һәм бу чыгымнарны каплау авырга туры килә.

# БЕЗНЕҢ СТУДЕНТ ДӨНЬЯНЫҢ ИҢ ЯХШЫ КОРЪӘНХАФИЗЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕНДӘ

**Коръәнхафизлар әзерләү үзәге студенты Габдрәхим Лотфуллаев Мисырда узган Халыкара коръәнхафизлар конкурсында катнашып, дөньяның иң яхшы ун коръәнхафизы исемлегенә керде.**



Әлеге халыкара конкурс Мисырда инде 21 нче тапкыр уздырыла. Конкурста 43 илдән йөздән артык коръәнхафиз катнашкан.

Конкурс тәмамланганнан соң Габдрәхимгә Мисырның вәкыфлар министры доктор Мохтар Жумга һәм әл-Әзһәр университеты вәкиле диплом тапшырган. Бу уңыш - Аллаһның мәрхәмәте һәм Корьәнхафизлар әзерләү үзәге, Казан ислам институты коллективының, шулай ук Габдрәхимнең үзенең дә зур тырышлыгы нәтиҗәсе. Г.Лотфуллаев Пермь шәһәрендә узган Бөтенроссия коръәнхафизлар конкурсында да беренче урынны алган иде.



# ЧИТТӘН КАРАГАНДА ЯХШЫРАК КҮРЕНӘ

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе мөфти Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН “БИЗНЕС Online” электрон газетасы укучыларының күпсанлы сорауларына җавап бирде. Ул Диния нәзарәте белән 2013 нче елның апреленнән җитәкчелек итә. Шуңа да беренче сорау бер ел эчендә нәзарәтнең нәрсәләргә ирешүе турында булды. Камил хәзрәт исә үз эшен үзе бәяләмәде, читтән караганда яхшырак күренәдер, дигән фикер белән генә чикләнде. “Канәгать булуым турында әйтсәм, бу минем тукталуымны, артка таба тәгәрәүне күрсәтәчәк”, - дип җавап бирде ул.**

### ИҢ МӨҺИМ ПРОЕКТ

Диния нәзарәте башлыгы булгач, нәрсәләр эшләргә җыенуы турында ул “БИЗНЕС Online”да булган үзенең беренче интернет-конференциясендә сөйләгән иде. Камил хәзрәт бүгенге көндә Диния нәзарәтенең иң мөһим проекты инвалид ятим балалар өчен балалар йорты булуы турында әйтте. Мөфтият балалар йорты өчен бина яки бина төзү өчен җир эзли. “Марафон, смс тавыш бирү үткәрелде, кешеләр 50 шәр сум һәм күбрәк тә җибәрделәр, - дип сөйләде мөфти. - Бер миллион сум тирәсе җыелды. Әлегә бу акча “Зәкят” фонды счетында ята, без аңа тимибез. Биналар сайладык. Башта Биектаудагы бинаны карадык, соңрак мондый бинага таләпләр күп булу сәбәпле яңа бина төзергә ки-рәктер, дигән фикергә килдек. Боровое Матюшинода мәчет һәм чиркәү төзү өчен бирәр гектар җир бүленеп бирелгән иде. Бәлки шунда төзергәдер, дигән фикер дә бар. Төрле вариантларны карыйбыз, яхшырагын сайларга тырышабыз. Бу бина физик мөмкинлекләре чикле булган ятим балалар өчен балалар йорты булачак”.

“Әлеге балалар йортына нинди милләт балаларын алачаклар?” - дип сорагач, Камил хәзрәт гаҗәпләнде: “Әлбәттә, милләтенә карамаячакбыз. Балалар барысы да мөселман, мөселман булмаган бала юк”. Бу гади булмаган балалар йорты ТР мөселманнары Диния нәзарәте каршында эшләячәк. Мөфти: “Безнең Ярдәм мәчете каршында Сукырларны тернәкләндерү үзәге бар. Эш барышында күп кенә тәҗрибә тупланды, төрле белгечләр белән таныштык. Хәзер без республикабызда андый белгечләр барлыгын беләбез. Шулай ук яхшы кешеләрнең күп икәнлеген дә... Яхшы кешеләр саны, чынлыкта, бик күп, һәм аларга бу сыйфатларын күрсәтү мөмкинлеге бирергә кирәк”, - диде.

“Безнең команда яшь, актив, кызыклы башлангычлар да күп”, - диде Камил хәзрәт. Команда заманча технологияләрне киң куллана икән. Мәсәлән, телефоннан теләсә кайсы илдә “Азан” радиосын тыңлау мөмкинлеге биргән программа эшләнгән. Россиядә мәчетләрнең, хәләл кибетләрнең һәм ашханәләрнең кайда урнашуын күрсәтүче программа бар. ”Машинада Мәскәүдән кайтып барганда, шушы программаны ачтым. Карасам, Түбән Новгород шәһәрендә хәләл кафе бар икән, - дип сөйләде Камил хәзрәт.- Кердек, намаз укып, ашап чыктык”...

Тиздән тулысынча татар телендә эшләнелгән өченче программа гамәлгә кертеләчәк, бу - Татарстанның 45 районы өчен намаз уку вакытлары. “Һәр район өчен без һәр намазның төгәл вакытын билгеләдек”, - диде Камил хәзрәт.

### КЫРЫМ: ЙӨРӘКЛӘРЕБЕЗ СЕЗГӘ АЧЫК

“БИЗНЕС Online” укучылары мөфтинең күптән түгел Кырымга булган сәфәре турында сорадылар. “Кырымга юл тотканда, андагы хәлне яхшы дип тә, начар дип тә әйтеп булмый иде, - дип искә төшерде Камил хәзрәт. - Ләкин без Диния нәзарәте буларак сәясәткә тыгылырга тиеш түгел, бу безнең максатка керми. Шуңа күрә баштан ук, килүебезнең сәбәбе - мөфти белән танышу һәм үзара мөнәсәбәтләр урнаштыру, дидек. Без телләребез охшашлыгы, тарихи бәйләнешләр турында әйттек. “Йөрәкләребез сезгә ачык, ярдәм кирәк икән – без булышырга әзер. Россия составына керү мәсьәләсендә, мин сәясәтче түгел. Сез үзегез сайларга тиеш. Нинди юлны сайласагыз да, без сезне хөрмәт итәчәкбез, чөнки без кардәшләр”, - дидек”.

Камил хәзрәт Кырымда “Хизбут-тәхрир” экстремистлык оешмасының 10 меңгә якын вәкиле булуы турында ишетүе, ләкин бер баруда объектив нәтиҗәләр чыгарып булмавы турында әйтте. “Чыннан да 10 мең микән, Кырым татарларының саны да 300 мең генә бит?”- дигән соравыбызга мөфти: “Безгә шундый санны атадылар”, - дип җавап бирде.

Ул шулай ук Кырым мөселман өммәтенең проблемалары турында да сөйләде: “Проблемалар бик күп. Тел проблемасы: алар милли мәктәпләр булмаганга бик борчылалар. 1944 нче елда сөрелгәнгә; кире кайткач, 4 сутый җирне һаман да бирмәүләренә үпкәләре бар...”

“Мәҗлестән тыш без аксакаллар шурасы белән очраштык. Аларның карашлары бөтенләй башка, - диде мөфти. - Бу бөтенләй башка кешеләр - мөхтәрәм картлар. Без бик күп уртак нәрсәләр таптык. Кемнеңдер кызы Казан дәүләт университетын тәмамлаган, кемнендер улы Ульяновскида яши. Идел буе татарлары белән аксакаллар бик тыгыз бәйләнештә”...

### ХАҖИЛАРНЫ КАЙГЫРТАБЫЗ

Укучыларыбызда хаҗ темасы зур кызыксыну уятты. Камил хәзрәт Татарстан өчен квотаның өчтән бер өлешкә артуын әйтте, ләкин аны Согуд Гарәбстаны арттырмаган: “Россия мөселманнары өчен квотаны Россиянең Согуд Гарәбстанындагы хаҗ миссиясе сорап ала. Ә инде Россиядә ул өлкәләр арасында бүленә... Россия өчен квота, гомумән алганда, киметелде: былтыр 20,5 мең булса, быел - 16,4 мең... Квота барлык илләр өчен дә кимеде, чөнки Мәккә шәһәрендә зур реконструкция бара”.

Алай да Татарстан өчен хаҗилар санына квотаны арттыралар: былтыр 1,2 мең булса, быел ул - 1,8 мең. “Мин бу сорауны күтәрдем, хатлар яздым, былтыр бездә 400 ләп кешенең хаҗга бара алмавы турында әйттем”, - диде Камил хәзрәт. Аның әйтүенчә, Россиянең башка төбәкләре Диния нәзарәтләре белән сөйләшүләр нәтиҗәсендә алар үзләренә бирелгән квоталардан Татарстанга да өлеш чыгарган.

Укучылар мөфтидән ни өчен хаҗ бәясенең елдан-ел артуы һәм быел 150 мең сум торуы турында сорадылар. Мондый сорауларны биргән укучылар хаҗ бәясе артуны валюта арту белән түгел, ә яңа мөфти килү белән бәйлиләр. “Безнең хаҗ миссиясе тәкъдим иткән хезмәтләр үз эченә бөтен нәрсәне ала, дип аңлатты Камил хәзрәт. - Иң кыйммәте - юл бәясе. Казаннан туры рейслар оештырылды. Казанда самолетка утырасың һәм син 5 сәгатьтән Согуд Гарәбстанында. Бу, билгеле, зур казаныш. Хаҗ бәясенә бөтен нәрсә дә кертелгән - кеше үзе белән кучтәнәчкә генә акча ала. Башка оешмаларга карасак, чагыштырсак - аларның бәяләре түбәнрәк тә булырга мөмкин. Ләкин алар автобус белән баралар яисә бу бәягә ашату кертелмәгән, ә Согуд Гарәбстанында ашамлыклар әзләү бик кыен... Үз пешекчең, үз табибларың булу бик яхшы. Монда бай һәм хаҗга акчаны кыенлык белән җыйган кеше арасында бернинди аерма юк. Керемгә калган акчаның күләме бик аз...

Без хаҗиларыбызны бик кайгыртабыз. Алар яшәячәк кунакханә номерларын карарга мин үзем бардым. Кунакханәләрнең бер-берсенә якынрак урнашуын, аларга җайлырак булуын телибез. Әгәр дә кеше хаҗга гомерендә бер тапкыр бара икән, ул аны уңайлы шартларда үтсен”.

**“БИЗНЕС Online”**

## БУ ШАТЛЫКНЫ ҮЗЕГЕЗГӘ ДӘ КИЧЕРЕРГӘ НАСЫЙП БУЛСЫН!

Әссәламе галәйкүм, хөрмәтле Камил хәзрәт!

Авыр эшегездә җиңеллекләр теләп, Аксубай районы Тактаны авылының үзәк мәчетенә йөрүче, ветераннар советы рәисе Сафа улы Хәлим абыегыз хат яза. Сезгә кадәр Госман хәзрәт Исхакыйны да, Илдус хәзрәт Фәизне дә күрергә Аллаһ насыйп итте. Әле Сезне күреп сөйләшкән юк, Аллаһ насыйп итсен.

Язуымның сәбәбе шул - рәхмәт сүзләре җиткерәсем килә. Авылыбызның имамы булып Илнар хәзрәт Сафиуллин хезмәт итә. Өйләнгән, өч баласы бар. Мәдрәсә тәмамлауга үзен мәчеткә имам итеп сайладык. Эшен белеп башкара. Беренче көннән үк бөтенебез белән дә уртак тел тапты. Мәчет авыл халкы ярдәме белән генә эшләп килә. Имамыбызга хезмәт хакын түли алмыйча авырсына идек. Аңа төрле өстәмә эшләр башкарырга туры килде. Инде менә сезнең имамнарны чынчынлап кайгыртуыгыз аркасында хәзрәтебез грант исе булды. Ул акчаларны алып файдалана да башлады. Мәчеткә балалар өчен өстәмә китаплар кайтартты. Язу тактасы белән укучылар өчен өстәлләр урнаштырды. Ниһаять, гади имамнарны кайгыртучы мөфти сайланды, дип без дә сөенешәбез. Имамнарыбызның дәрәҗәсен күтәрүче җитәкче күптән кирәк иде. Бу эшегез дәвамлы булсын, имамнарга китергән шатлыкны үзегезгә дә кичерергә насыйп булсын. Тирә-юнегездә бары тик тәүфикълы бәндәләр, эшегездә җиңеллекләр китерә торган кешеләр булсын. Насыйп булса, бер күрешербез әле.

**Хәлим абыегыз ӘХМӘТҖАНОВ,**
**Аксубай районы**

# ДИН КАРДӘШЕҢНЕ ЯРАТУ ТУРЫНДА

**Пәйгамбәребез (с.г.в.): "Иман китермичә җәннәткә кермәссез, бер-берегезне яратмыйча иман китермәссез", - дигән (Бохари, Мөслим). Шулай ук бер хәдистә болай диелә: "Минем өчен яратышканнарны Мин дә яратачакмын" (Әхмәд).**

Аллаһы Тәгалә безне бер-беребезне яратырга өнди һәм болай ди: "Дөреслектә, иман китереп изге гамәлләр кылган кешеләр арасында Аллаһы Тәгалә мәхәббәт вә дуслыкны булдырыр" ("Мәрьям" сүрәсе, 96 нчы аять).

Шулай итеп, мәхәббәтебезнең көчсезлеге иманыбызның көчле булмавыннан, игелекле гамәлләребезнең аз булуыннан килә. Иманыбызны ныгытыр өчен нәрсә эшләргә кирәк соң? Әнәс (р.г.) сүзләреннән Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) болай дип әйтүен тапшыралар: **"Иман ләззәтен өч сыйфаты булган кеше тояр. Аллаһы Тәгаләне һәм Аның Илчесен башкаларга караганда күбрәк яратучы, башка кешене Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен яратучы һәм Уттан котылырга теләгән кебек, аннан Аллаһы Тәгалә коткаргач, имансызлыкка кире кайтырга теләмәүче кеше"** (Бохари, Мөслим).

Әбу Һөрайра (р.г.) сүзләреннән Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) болай дип әйтүен тапшыралар: "Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә сорар: **"Кайда Минем Бөеклегем өчен бер-берсен яратышканнар?! Мин бүген аларны Үземнең күләгәм белән каплыйм. Дөреслектә, ул көнне Минем күләгәмнән башка күләгә булмас"** (Мөслим).

Әбу Идрис әл-Хәуләни сүзләреннән: "Димәшкъ шәһәренең бер мәчетенә кергәч, мин кешеләр арасында басып торучы ап-ак тешле бер егетне күрдем. Кешеләр аңа нининдидер сорауларда килешә алмаганда мөрәҗәгать итәләр һәм ул әйткәнне дөрес дип кабул итәләр иде. Аның турында сораштыра башлагач, миңа: "Бу Мөгаз бине Җәбәл (Аллаһы Тәгалә аннан разый булса иде)",- дип җавап бирделәр. Икенче көнне мәчеткә иртәрәк килдем, ләкин ул миннән алда килгән һәм намаз укый башлаган иде. Ул дога кылып бетергәч, аның янына килеп сәлам бирдем һәм: "Аллаһы Тәгалә белән ант итәм, мин сине Аның ризалыгы өчен яратам!"- дидем. Ул миннән: "Аллаһы Тәгалә өчен дип ант итәсеңме?" - дип сорады. Мин: "Ант итәм!"- дип җавап бирдем. Ул тагын бер тапкыр: "Аллаһы Тәгалә өчен дип ант итәсеңме?"- дип сорады. Мин: "Ант итәм!"- дип җавап бирдем. Шуннан соң ул мине үзенә тартып китерде дә болай диде: "Шатлан, чөнки мин Аллаһы Тәгалә Илчесенең: **"Аллаһы Тәгалә әйтте: Минем өчен яратышканнарны, минем өчен очрашучыларны, Минем өчен бер-берсенең хәлләрен белүчеләрне, Минем өчен бернәрсәләрен дә кызганмаучыларны Мин дә яратачакмын"**, - диюен ишеттем" ("Әл-Муватта"да имам Мәлик китергән ышанычлы иснад белән ышанычлы хәдис).

Ике дус турында сөйлисем килә. Габдулла фәкыйрь гаиләдән була. Аллаһы Тәгалә ярдәме белән ул зур шәһәрнең югары уку йортына укырга керә. Яхшы укый, ләкин акча юклыктан интегә. Габдулланың дуслары күп булып, алар арасыннан иң якыны Мостафа исемле егет икән. Көннәрдән бер көнне Мостафа әти-әнисе белән сөйләшеп, Габдуллага тулай торактан үзләренә күчәргә тәкъдим итә. Алар бертуганнар кебек яши башлыйлар, бөтен җиргә дә бергә йөриләр. Мостафа беркөнне үзе яратып йөргән кызны Габдулла белән бергә күрә. Җаны әрнесә дә, әти-әнисе белән сөйләшеп, алардан Габдуллага кызны сорарга һәм туйны әзерләргә булышуларын үтенә. Берничә ел үтә, Габдулла башка шәһәргә күчеп китә, тырышып эшли башлый һәм шәһәр башлыгы була. Ул берничә тапкыр үз шәһәрендә калган Мостафага булышырга тырышып карый, ләкин Мостафа ярдәмне кире кага, аны хәер дип исәпли.


Еллар уза, Мостафа бөлгенлеккә төшә һәм дусты яшәгән шәһәргә күченеп килә. Хакимият бинасына кереп, шәһәр башлыгы белән очрашырга теләвен әйткәч, аны кире боралар. "Мин бит аның дусты – Мостафа!" – дип гаҗәпләнә ул, ләкин аңа: "Нәкъ менә сезне кертмәскә кушылды да инде", - дип җавап кайтаралар. Озак уйлап тормастан, Мостафа дустының өенә китә, ул бит аның хатынын белә, аларның туйларын ясауда булышты. Кыңгырау төймәсенә басып, ишек төбендә торганда Мостафа эчтә кемнеңдер булуын тоя һәм аңа ачарга теләмәүләрен аңлый. Мостафа бик рәнҗи һәм елый, үзе белән мондый хәл булуына һич ышана алмый. Дустының өеннән чыгып, урам буенча китә, бөтен дөнья аңа каршы булып күренә башлый. Шул чагында аңа бер карт эндәшә: "Сиңа нәрсә булды?" Мостафа җавап кайтара, болар сөйләшеп китәләр. Мостафа эшсез калуы, иң якын дустының хыянәт итүе турында сөйли. Карт аңа үзенең зәркәнче булуы турында әйтә һәм эш тәкъдим итә.

Вакыт уза, көннәрдән беркөнне алар кибетенә кулына букча тоткан бер карт килеп керә. Ул Мостафага мөрәҗәгать итә: "Мин хаҗга китәм, менә бу букчаны синдә саклауга калдырам, кире айтсам – бирерсең, өч ай узгач та кире кайтмасам, ул - синеке". Өч ай уза, әмма сәер карт күренми. Мостафа букчаны ачып караса – ул алтын белән тулы икән. Ул хуҗасы белән сәүдәләрен киңәйтеп җибәрә. Беркөнне кибеткә әнисе белән бер кыз килеп керә. Бу кыз Мостафага бик охшый. Алар танышалар, яратышалар һәм өйләнешергә булалар. Бу кыз бай гаиләдән булганга күрә, туйга кунаклар күп килә. Мостафа кунаклар арасында элеккеге дусты Габдулланы күреп, бик дулкынлана, Габдулла белән очрашырга теләми һәм кунаклар арасында югалырга тырыша. Ләкин чыдый алмыйча микрофон янына килеп: "Мин сезнең безне котларга килүегезгә бик шатмын. Ләкин арагызда мин күрергә теләмәгән шәһәр башлыгы да бар. Болай дип әйтүем өчен гафу итегез, ләкин җаным әрни. Мин сезгә аның турында сөйләргә телим. Без иң якын дуслар идек. Ул безнең йортта яшәде. Мин сөйгән кызымнан баш тартып, аларның туйларын оештырырга булыштым, ләкин ул зур кеше булгач, миңа ярдәм итмәде, хатыны да ишек ачмады. Сез моны аңлый аласызмы? Дуслар белән шулай итәләрме?" – дип ул күз яшьләрен кеше күрмәсен өчен битен учлары белән каплый.

Габдулла микрофон янына килеп сөйли башлый: "Әйе, дустым сөйләгәннәр барысы да дөрес. Ләкин ул кайбер нәрсәләрне белми. Мин аңа һәрвакыт булышырга теләдем, ләкин ул горурлыгы аркасында минем ярдәмемне кабул итмәде. Эшемә ярдәм сорап килгәч, мин аны, холкын белгәнгә күрә, үзен миңа бурычлы булып исәпләмәсен өчен генә кабул итмәдем. Хатыныма да ишек ачмаска куштым. Шуннан соң гаилә дустыбыздан өебездән чыгучы кешене саклап торып, аңа эш тәкъдим итүен үтендем, хезмәт хакын түләргә булыштым. Алтын сатуларын белеп, бизәнү әйберләрен сатып алдым, уйлап чыгарган сәбәп белән әтиемне дустым эшләгән кибеткә җибәрдем һәм аңа алтын бүләк иттем. Эшләре ничек баруын белер өчен, кибеткә сеңлем белән әниемне җибәрдем. Алар берберсенә гашыйк булганнар һәм, күрүегезчә, менә хәзер өйләнешәләр. Мин сезне котлыйм!"

Аллаһы Тәгалә: **"Мөэминнәр дин буенча, әлбәттә, бер-берсенә кардәшләрдер"**, - ди ("Хуҗүрат" сүрәсе, 10 нчы аять). Монда ачык әйтелгән – кардәшләр булыр өчен иманлы булу җитә. Әгәр дә кемдер, бары тик аның җәмәгате генә аңа кардәш була, ди икән ул Аллаһы Тәгалә сүзләрен үзгәртә. Игътибар итегез! Аллаһы Тәгалә безне кардәшләр ди, дуслар яки иптәшләр дими. Чөнки дуслык һәм иптәшлек теләсә кайчан бетәргә мөмкин. Ә туганнар ничек кенә талашмасыннар туган булып кала. Бертуганнардан да күбрәк сугышканнарны күргәнең бармы? Ләкин алар барыбер туган булып кала. Бер-беребезне яратыр өчен бик күп сәбәпләр барлыгын аңлагансыңдыр инде. Ә максатыбыз бер безнең – башкалар алдында исламның гүзәллеген күрсәтү һәм аны тарату. Без төрле төркем мөселманнарның башкаларга Аллаһы Тәгалә динен җиткерүен күрәбез, алар моның өчен төрле ысуллар кулланалар: кемдер җәмгыятькә күбрәк файда китерү һәм Аллаһы Тәгалә ризалыгына ирешү өчен белем ала, кемдер газеталар чыгара һ.б. Барыбыз да туганнар булып калабыз.

Мәхәббәтне кире какма, мәхәббәттән курыкма. Ләкин исеңдә тот – нәрсәне яратсаң да, син аны Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен генә яратырга тиеш. Һәм Пәйгамбәребез (с.г.в.) догасын укы: **"Йә Раббым! Синең мәхәббәтеңне һәм сине яратучылар мәхәббәтен сорыйм".**



# КОРЪӘННЕ АКЧАГА УКЫРГА ЯРЫЙМЫ?

Коръән уку, хәтем кылу – гыйбадәтнең бер төре булып тора. Андый эшләрдә нинди дә булса түләү алынырга тиеш түгел. Бу – гыйбадәт кылуның төп принцибы. Ләкин имам, мәәзин, вәгазьче һәм Коръәнгә өйрәтүче (һәр мөселманның бурычы булмаган вазыйфаларны башкаручылар) бу кагыйдәдән искәрмә булып торалар. Бу вазыйфаларны түләүсез башкарырга әзер булучылар бик аз калу сәбәпле аларны түләүле итү традициясе барлыкка килә. Коръән укыган өчен нинди дә булса түләү алуны күп кенә фикыһ галимнәре тыелган гамәл дип исәпләгәннәр. "Шәрхел-Һидая" китабы авторы Таҗушшария: "Түләү алып Коръән укыган вакытта аны укыган кешегә дә, мәрхүмгә дә бернинди дә савап булмаячак", - ди. "Әл-Биная фишәрхигел-һидая" дигән китабында ул болай дип яза: "Коръән укыган өчен түләү алган кеше – гөнаһлы кеше була".

Габдрахман бине Шибел (Аллаһ аңардан риза булса иде) тапшырган хәдистә Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) мондый сүзләре китерелә: "Коръән укыгыз, ләкин аның өчен түләү алмагыз..." Бурайда (Аллаһ аңардан риза булса иде) Аллаһ Рәсүленең (с.г.в.) шундый сүзләрен тапшыра: "Кем дә кем Коръән укый һәм моның өчен нинди дер түләү ала, ул Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә каршына йөзен югалткан килеш торып басар".

Шуның белән бергә фикыһ буенча кайбер галимнәр Коръән уку өчен ниндидер түләү алу – рөхсәт ителгән гамәл дип исәплиләр. Алар Габдулла бине Габбас (Аллаһ аңардан риза булса иде) тапшырган хәдистән чыгып шундый фикергә килгәннәр. Ә ул хәдистә Пәйгамбәребезнең (с.г.в.): "Сез түләү ала алган вазыйфаларның рөхсәт ителгәне - Коръән уку булыр", - ди. Бер-ике мисал китерик. Хәнәфи мәзһәбенең фикыһ белгече Фәхреддин Казыхан шундый фәтва чыгарган: "Борынгы заманнардан бирле казна хафизларга акча бүлә торган булган, халык Изге Коръәнгә карата зур кызыксыну күрсәткән. Аннан соң хөкүмәт бу тема белән кызыксынмый башлаган һәм халыкта да мондый кызыксыну сүнгән. Коръән укыган һәм аңа өйрәткән өчен түләү алуга юл ачмыйча, Коръәннең әһәмияте кимер дип шөбһәләнеп, кешеләр аның өчен түләү алу рөхсәт ителгән эш дип исәпли башлаганнар". "Әл-Фәтавагел-Һиндия" хезмәтендә болай дип әйтелгән: "Коръән укыган өчен түләү алу турында чыгарылган фәтва автономияле булып тора". Димәшкъ мөфтие Мәхмүд Хәмзә дә Коръән укыган өчен ниндидер түләү алу мөмкин дип исәпләгән һәм бу турыда "Рафугелгышава ән җавази әхзигел-уҗрати алягет-тилава" исемле хезмәт язган.

Шулай итеп, Изге Коръән гыйбадәт кылу максатында укылырга һәм тыңланырга тиеш. Моны акча өчен эшләргә кирәкми. Коръән укыган һәм аңа өйрәткән кеше, иң беренче чиратта, Аллаһның ризалыгын һәм савап алу турында уйларга тиеш. Бу яктан караганда, Коръән укыган кеше ниндидер түләү турында уйларга тиеш түгел, ә Коръән укуны сораган кеше, үз чиратында, аны укыган кешегә хөрмәт күрсәтеп, аны тиешенчә бүләкләүдә саранланмаска тиеш. Ә Аллаһка барысыннан да яхшырак мәгълүмдер.

*Татарстан мөфтие Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН*

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИҖАТЫНДА ИСЛАМ АҺӘҢНӘРЕ

**Мөхтәрәм Тукаебызның иҗаты буыннарга мирас булып, калебләремезне тетрәндергеч афәт, каршылыклы замана еллары аша безгә дә килеп җитте. Бүген җир йөзендә яшәгән әһле ислам вә башка диндә торган Раббымызның һәр бәндәсе Тукайга үзенең итагате илән ихтирам хисләрен багышлый.**



Вәхшилек елларында "дин ул халыклар агуы" дигән хорафат афәт булып халыклар башына төшкән заманда, 30 меңгә якын дин әһеле Соха тайгаларында, Воркута шахталарында, Балтыйк – Ак диңгез каналларында газапланып үтерелгән вакытта дистәләгән "тукайчылар" газиз шагыйребезнең асыл шигырьләрен халыктан яшерделәр. Тукайдан башта "демократ", аннан "социалист", соңрак имансыз бер "атеист" ясарга омтылып, гәҗит, журнал битләрен нинди генә мәкаләләр белән тутырмадылар. Заман вә түрәләргә ошарга ашкынган "фәнни"ләрдән кемнәр генә юка брошюралар, калын китаплар язып, кемнәр генә зур дәрәҗәләр алып, кемнәр генә "атказанмады"?!

Бүген, ул хорафат идеология чүплеккә ташланганда, ниһаять, газиз Тукаебызның иҗаты турында дөреслекне әйтер заман килеп җитте.

Тукай ислам динен "тамырыннан корытырга", "дин әһелләрен кырып ташларга" түгел, ә киресенчә, ислам динен, муллаларны якларга чакырды. Үзенең "Дусларга бер сүз" дигән шигырендә әдип:

***Бу эшләрдә зәхмәтләмик муллаларны,***
***Дин эшендә башчы итик без аларны...***
***Барып керик хөрриятнең кочагына,***
***Тәрәкъкыйның күкләренә очмагына;***
***Бу егетләр безне дөнья оҗмахына***
***Кулдан тотып җитәклиләр, белең, имди,*** – дип язды.

Дөнья тарихында Гете, Һейне, Пушкин, Жуковский, Лермонтовлар Коръән-Кәрим аятьләрен шигъри юлларга салдылар. Пушкин үзенең 9 шигырендә Коръәннең 75 аятен тәфсир кылды. Алар кебек үк мөхтәрәм Тукаебыз да үз иҗатында бихисап мәртәбәләр Раббымызның олуг нигъмәте Коръән-Кәримгә мөрәҗәгать итә. Бу җөмләдән газиз Габдулла Тукаебызның иҗаты Аллаһу Раббымызның олуг нигъмәте Коръән белән сугарылган дисәк тә нахак булмас. "Дусларга бер сүз", "Тәәссер", "Китап", "Таян Аллага", "Туган тел", "Шиһап хәзрәт", "Кыйтга", "Васыятем", башка бихисап шигырьләре барлык иманлы кешеләргә дәлил булып тора.

Кадер киче якынлашкан мизгелдә Коръәннең "Кадер" исемен йөрткән 97 нче сүрәсен Тукаебызның шигъри ысул белән тәфсир кылуы барчабызны да гафиллектән уята да уйга сала. Галәмнәр хуҗасы Аллаһу Раббымызның мөбарәк сүрәсендәге: "Иннәәә әнзәлнәәһү фии Ләйләтил кадр", - ягъни, без Коръәнне чынлыкта Кадер кичәсендә иңдердек, – дигән сүзләрне Тукай:

***Бу Кадер кич, елда бер кич, барча кичләр изгесе;***
***Сафланыр таптан бу кич мөэмин күңелләр көзгесе,*** – дип тәфсир итә.

"Вам әәә әдрәәкә мәә Ләйләтүл кадр", – Кадер Раббыгыз каршында иң шәрәфәтле кичәдер, – дигән Аллаһыбыз сүзен Тукай:

***Сафланыр ул, пакьләнер, бик зур Ходайның дәүләте;***
***Һәм төшәр ул көзгеләргә күк капусы шәүләсе,*** – дип яза.

"Ләйләтүлкадри хайром мин әлфишәһр", – ул бер кичә үзе мең айдан да изгерәк, – дигән Аллаһу Хак Тәгаләнең сүзе Тукайда:

***Шул капугдан күндерербез Тәңребезгә бер теләк:***
***Бер Кадер киче Тәңре каршында мең айдан да изгерәк.***

Җәнабел Хак Сүбхәәнәһү вә Тәгалә "Ниса" (10 нчы аять) сүрәсендә: "Иннәллидинә йәкүлүнә әмьүәләл – йәтәмә зульмән иннәмә йәкүлүнә фии бүтуниһим нәра", – ягъни золым юлы белән ятимнәр малын ашаган кешеләр ахирәттә карыннарына ут ашарлар, дип залимнәрне кисәтте. Раббымыз тарафыннан Коръән белән тәсдыйкъ ителгән дүрт төрле сәдака бар: зәкят, гошер, фитыр, фидия. Бу сәдакалар – тәгамүммискин. Ягъни мескеннәр, фәкыйрьләр, толятимнәр хакы булган, үтәү өчен катгый боерылган фарыз, ваҗиб сәдакалар. Аларны тол-ятим, зәгыйфь булмаган кешегә (муллага, абыстайга, мәчеткә) бирү зур гөнаһ, исламга хыянәт икәнлегенә җан-тән рәнҗеш илән хурланган Тукай:

***Ул мәләикләр* җыярлар, тол-ятимнәр яшьләрен,***
***Барча көчсезләр, зәгыйфьләрнең аһын, каргышларын,*** - дип әүвәлге һәм бүгенге өммәтнең дини, иҗтимагый, сәяси вә икътисадый мәнфәгатьләрен кайгыртмаучы, дөнья малын ауламакка омтылган комсыз "ачкүзләргә" нәфрәтен белдерә.

Коръән-Кәримне иркен, тулы иттереп мәгънәви шигырьгә салган шагыйрьнең тәфсиле һәр иманлы кешегә дәрес, үгет-нәсыйхәт булып торуына без ихлас күңелдән горурланабыз. Шуңа күрә дә без Раббымызның барлыгына, берлегенә, Аның олуг нигъмәте Коръән-Кәримгә, Аллаһымызның фарыз, ваҗибләренә ышанабыз. Мөхәммәд галәйһиссәламнең сөннәтенә ияреп, тормышыбызда бәндәчелек белән булган хата вә гөнаһларыбызны Рамазан шәрифнең мөкатдәс Кадер кичәсендә вә аның хәерле дәвамында төзәтергә ашыгабыз.

Шулай булуга карамастан, аерым зыялылар арасында әле бүген дә Тукайның ислам диненә карата мөнәсәбәте бихисап бәхәсләр тудыра. Коммунистик тәгълимат белән сугарылган зыялыларыбыз арасында, ни кызганыч, Тукай "динсез, имансыз" булган, дип, шагыйрьне атеистлаштырырга омтылучылар да бар иде. Әйтерсең лә, Тукай бу затларның фикерләрен үз заманында ук белгән һәм үзенең "Тәәссер" дип аталган шигырен язып, Раббымызның "Бәни Исраил" исемен йөрткән мөбарәк аятенә бинаэн булып, киләчәктә шөбһәләнүчеләргә әманәт әйтеп калдырган. "Вә нүнәззилү минәл Коръәни мәә һүә шифааа вә рәхмәтүллил мөэминиин", ягъни без мөэминнәрнең күңелләренә шифалы аятьләрне вә Коръәннән рәхмәтле хөкемнәрне индерәбез, дигән Хак Тәгалә кәлимәсен газиз Тукай мәгънәви тәфсир кылган:

***Гомернең иң читен, җайсыз, уңайсыз бер минутында,***
***Әгәр янсам каты хәсрәт вә кайгының мин утында,***
***Укыйм тиз-тиз күңелдән гаҗаиб сүрә Коръәннән, –***
***Газаплар мәгънәви бер кул илән алынадыр җаннан.***
***Оча дилдән** бөтен шикшөбһәләр, һәм мин җылый башлыйм:***
***Яңакларны мөкаддәс күз яшемлә энҗели башлыйм.***
***Бөтенләй сафлана күңлем; укыйм иман, булам мөэмин.***
***Киләә рәхәт, җиңеллекләр, хәлас булам*** авыр йөкдин.***
***Ходайя! Син тыйган эшләр тәмам әкътаг вә әбтәр****, дим;***
***Иям баш сәҗдәгә: "Аллаһе Хак! Аллаһеәкбәр!" – дим.***

Бу юлларны укыгач, Тукайны динсезлектә гаепләргә кем генә кыюлык табар икән?!

Шул ук вакытта, сабыйлык елларыннан башлап, вафатына кадәр әдипнең гомере вә иҗаты фаҗигале, каршылыклы кичерешләр белән сугарылган. Бу кичерешләр ислам диненә вә аның шәригатенә каршы атеист булудан түгел, ә явыз ният илән дөнья малын ауламак өчен гамәлдә-хәрамда саташкан "кибән чалма кибәк башта: ишан булган, имеш, хайван!" кебек "сорыкортларга" каршы булудан гыйбарәт иде. Менә шушы хорафат ислам алгарышына афәт булып киләчәген моннан 14 гасыр әүвәл фәһемләгән Раббымызның хәбибе Мөхәммәд галәйһиссәлам үзенең мөбарәк хәдисендә:



"Өммәтем өчен, Дәҗҗалдан бигрәк, азгын имамнар куркынычлырак", - дип өммәтенә әманәт әйтеп калдырды. "Дәҗҗалны азмы-күпме һәркем белергә вә аның яманлыгыннан сакланырга мөмкин, әммә вә ышанычлы, диндар вә тәкъва исем белән йөрүче явыз имамнарның хакыйкатьләрен тану күп кешеләр өчен мөмкин түгел. Шул сәбәптән боларның өммәт өчен булган зарарлары Дәҗҗал зарарыннан күп мәртәбә артык булуында шөбһә юк", - диде Ризаэддин хәзрәт Фәхретдин.

Г.Тукай заманында гына түгел, бүген дә үзен "ишан" санап өйдән-өйгә йөргән, дәүләт-мәмләкәтләрне гизгән, бик тә кыю, вә ләкин бик тә надан вә комсыз, баш миенең бер ярымшарында "джип", икенчесендә "коттедж" утырган руханилар, ни кызганыч, Казан урамнарында гына түгел, мәчетләрендә дә күренгәли. Моннан бер гасыр әүвәл, әйтерсең лә, бу затларның XXI йөзнең башында булачакларын Тукай сизгән. Менә шул "муллалар"га ачулы пафос белән: "Күңелдә утлары сүнгән, вә вөҗдан майга капланган: "Әгүзе", дип кенә төшмәс, муенга шайтан атланган. Менә шул чаклы ялкау, шундый хайваннар да руханый! Түбәнлек бу, кабул итмәс үзенә изге рух аны!" – дип шагыйрь катгый тәнкыйтен белдерә. Ни өчен? Чөнки бүген Җир йөзендә яшәгән, сан ягыннан миллиард ярымга җиткән, ислами тәгълиматның хаклыгына итагать кылган бәндә "дин эшендә башчы" булган түрәне гаделлек белән сугарылган, бөтен изгелекләрне үзенә җыйган, һәрьяклап төгәл булган камил, галим, әүлия дәрәҗәсендә күзаллый. Ә чынлыкта бу затның камил түгеллеген үзе күргәч, ышанычы югала, кайгыхәсрәткә уралган күңеле юаныч таба алмый, миһере өзелә. Мөнбәрдә утырган "кибән чалма, кибәк баш"тан, мәчеттән бәгырь киселә.

Бүгенге вазгыятьтә Россиядә вә газиз Татарстаныбызда мөселманнарның мәчетләргә йөрмәвенең сәбәбен аларның исламнан бизүеннән түгел, ә мөәзин, мулла, имам хәзрәт абруеның халык алдында бик тә түбән булуыннан эзләргә кирәк.

Милләткә, ата-анага, нәселнәсәбәгә хаклыкка баруда тугры булып, планета-Җирдә тереклек кылган бер генә җан иясен дә рәнҗетмичә яшәү – ул Аллаһ Раббымызның бәндәгә үтәү өчен боерылган әманәте икәнлегенә Тукай үз иҗатының һәр җөмләсе белән басым ясый. Җәнабел Хак Сүбхәәнәһү вә Тәгалә мөбарәк "Әгъраф" сүрәсе (74 нче аять) белән: "...фәз-күрүүү әлләәә'әллаһи вә ләә тәгъсәү филәрдый мөфсидин", ягъни Җир йөзендә Без тереклек кылганнан соң көферлекләр кылып, хыянәтләр белән бозыклык кылмагыз, – дип бәндәгә боера. Димәк, милләтнең йөзенә кызыллык китермә. Шул милләттән әһле ислам-мөселман булган атаң-анаң, нәсел-нәсәбең белән горурлан. Халкыбызның "татар" этнонимы булып тупланганлыгына ихлас горурлык белән сугарылган Тукай:


***Күңелем белән сөям бәхтен татарның,***
***Күрергә җанлылык вактын татарның,***
***Татар бәхете өчен мин җан атармын:***
***Татар бит мин, үзем дә чын татармын,*** – дип яза Тукай "татарлыгы" – ул чын демократик милләтчелек. Шагыйрь иҗатыннан шовинистлыкның мыскалын эзләсәң дә таба алмыйсың. "Милләтне күтәрү" өндәмәсе – ул глобаль таләп. "Гомум халыкны күтәрү" төшенчәсе – ул утопия. Бер милләттән торган татар халкы үзенең горефгадәте, аңы, аһәңе, рухи халәте, дөньяга карашы – идеологиясе төрле булу сәбәпле, изгелеккә бөтен татарны бер мәлдә күтәрү мөмкин түгел. Милләтне күтәрергә телибез икән, татарның аң-әхлак ягыннан алдынгы улларын, кызларын, дин вә фән бергәлегендә прогрессив фикер ияләрен җитештерү, үстерү, күтәрү өчен ихлас тырышу зарур.

Бу - газиз Тукаебызның безгә әйтеп калдырган мөкатдәс әманәтедер.

* Мәләикләр – фәрештәләр.
** Дилдән – күңелдән.
*** Хәлас булам – азат булам.
**** Әкътаг вә әбтәр – кирәксез һәм яраксыз.

**Харис хәзрәт САЛИХҖАН**

# АСЫЛ МАКСАТЫҢНЫ ОНЫТМА!



**Намаз укырга теләп, аның фарызлыгын аңлап, Аллаһ кушканча яшәргә омтылып яшәүчеләр бихисап. Күп очракта алар нәкъ менә нәрсәдән башлап җибәрергә икәнен белми. Догалар ятларгамы, Коръәннән сүрә-аятьләр өйрәнергәме, дип сораштыра. Ләкин иң беренче чиратта безгә намазның исламдагы һәм кеше тормышындагы урынын һәм намазга баскан кешенең нинди өстенлекләргә ия булганын белү кирәктер.**

Диннең нигезе - шәһадәт. Ягъни Аллаһтан башка илаһ юк һәм Мөхәммәд (с.г.в.) Аның илчесе, дигән сүзләр. Ә диннең җидары, яки стеналары - намаз. Әлбәттә инде, нигездән башка стеналар тора алмаган кебек кеше дә иң беренче чиратта Аллаһны танырга, Пәйгамбәребез Мөхәммәдне (с.г.в.) Аның Рәсүле, кешеләрне туры юлга өндәүчесе итеп кабул итәргә тиеш. Аллаһны танып, Аның кануннары белән яшәргә керешкән кеше, әлбәттә, намазга килеп, Коръән буенча яшәргә омтыла башлый. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) хәдисе бар: “Намаз - диннең терәге. Һәм шулай ук аның нуры. Кем намазны торгызды, ягъни укыды - ул динне торгызган була. Кем намазын ташлады, ул динне җимергән кебек була”. Бу җидарны җимереп, йортны ишкән кебек. Шуңа күрә тагы бер хәдистә: “Намаз - исламның башы”, диелә. Ягъни әгәр дә кеше, исламны өйрәнеп, Аллаһ кушканча яши башларга телим, ди икән, ул беренче эш итеп кулына “Намаз уку тәртибе” китабын ала.

Намаз укучы кешенең намазы, аны начарлыклардан һәм фәхеш гамәлләрдән тыярга тиеш. Аллаһы Тәгалә бу турыда Коръәндә дә әйтеп уза: “Дөреслектә, намаз кешене начар һәм фәхеш гамәлләрдән тыя” (“Гәнкәбут (Үрмәкүч)” сүрәсе, 45 нче аять).

Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) көдси хәдисендә (көдси хәдисләрне илаһи хәдисләр дип атап йөртәләр, алар Пәйгамбәребезгә (с.г.в.) вәхи аша иңгәннәр) Аллаһы Тәгалә әйтә: “Мин кешегә көненә биш вакыт намаз укуны фарыз кылдым. Вакытында намаз үтәү - мөэминнәр өчен генә фарыз кылынды”. Әлеге хәдистә тагын мондый сүзләр бар: “Мин Үз-үзем белән килешү төзедем. Кем намазны үз вакытында үти, аның урыны җәннәттә булыр”. Икенче риваятьтә әйтелә: “Җәннәткә керү белән, көнлек ризыкны вәгъдә кылдым. Ә кем намазны үтәмәгән, бу кешегә минем вәгъдәм юк”.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: “Кыямәт көнендә иң беренче сорау намаз турында булыр. Әгәр дә ул намаз хәерле булса, бөтен гамәле дә яхшы булыр. Әгәр дә начар булса, калган гамәлләре дә начар булыр”. Икенче хәдистә: “Әгәр дә мөселман кешесе тиешенчә тәһарәт алып, шуннан үзенең намазын үти икән, аның гөнаһлары көз көне коелган яфраклар кебек коелып төшәр”, - диелгән (хәдисләрне Әхмәд, Әбү Дауд, Тәбарани риваять итә). Шулай булгач, һәр мөселман кешесе өчен намаз фарыз булды. Исламда аның урыны бик тә зур. Кешенең үзенә дә намаз уку әйтеп бетергесез тынычлык бирә, үз-үзенә ышаныч артуга, һәрвакыт тыныч күңел белән йөрүенә сәбәпче булып тора. Бары намаз укып кына кеше яшәү мәгънәсен аңлый башлый. Күңеле тынычлана, чөнки Аллаһ аның догаларын кабул итеп, гөнаһларыннан азат итә.

Намаз мәсьәләсендә бик тә мәшһүр тагын бер хәдис бар. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: “Ничек уйлыйсыз: әгәр берәрегезнең ишек төбеннән елга агып торса һәм ул шул елгада көненә биш мәртәбә юынса, тәнендә берәр кер калыр идеме?” Сәхабәләр: “Юк, калмас”, - дип җавап бирәләр. Шуннан соң Мөхәммәд галәйһиссәлам: “Биш вакыт намаз да нәкъ менә шуның кебек намаз укучыдан гөнаһларын юып төшерә”, - ди.

> ***“Кыямәт көнендә иң беренче сорау намаз турында булыр. Әгәр дә ул намаз хәерле булса, бөтен гамәле дә яхшы булыр. Әгәр дә начар булса, калган гамәлләре дә начар булыр”.***

Кеше исламга төрлечә килә. Кемгәдер дин турында сөйләп кызыктыру да җитә. Ә кайберәүләргә аның фарыз икәнен аңлап үти башлар өчен еллар кирәк. Без бик еш, намаз укырга өйрәнәсем килә, ләкин ничек тотынырга гына белмим, диюче кешеләрне очратабыз. Андыйлар барыбер өметле. Ә кайберәүләр, юк, намаз минем өчен түгел, миннән булмый, ди. Менә мондыйлар белән инде күпкә авыррак. Чөнки аларның дингә тартылу, намазга басу теләге юк. Ә кеше бар күңеле белән нәрсәне дә булса теләсә, ул аны булдыра. Бигрәк тә Аллаһ ризалыгы өчен берәр гамәлне эшләргә телисең икән, һичшиксез, Ул Үзе ярдәмен бирә. Ә Аллаһ ярдәме ул иң көчле әйбер. Шуңа да намаз укымасак та: “Мин укырга телим. Аллаһым, Үзең миңа ярдәмеңне бир”, - дип йөрергә кирәк. Ә кайберәүләр намазга басып, Аллаһ кушканча яшәргә теләсәләр дә булдыра алмыйлар. Әйтерсең лә, аларны нидер тотып тора. Моның төп сәбәбе – әйләнә-тирәдәгеләр. Кайвакытта кеше намазга басарга теләгәнен берәр якынына әйтсә, син нәрсә, пенсиягә чыккач та өлгерерсең әле, дип куялар да теге кешенең теләге кими төшә. Ә бу аның гыйлеме юклыктан, иманы нык булмаудан килә. Шуңа да кешегә иң беренче чиратта Аллаһ, ислам, Пәйгамбәребез (с.г.в.) турында күбрәк белергә, бу мәгълүматларны бирә ала торган кешеләр белән аралашырга кирәк.

Кайбер кеше динне авыр бер йөк итеп кабул итә. Көненә биш тапкыр намаз уку, рамазан аенда ай буе ач тору, малыңның бер өлешен зәкят итеп түләү, хәрамнан тыелу, хатын-кызларга капланып йөрү һ.б. Чынлыкта болар барысы да безгә Аллаһның рәхмәте итеп җибәрелгән. Намазның файдалары нинди зур булуын үзе укыган кеше генә аңлыйдыр. Изге рамазанда ай буе ураза тотуның да рәхәтен үзе кичергән кеше генә беләдер. Аллаһы кешеләргә авырлык теләми. Һәм адәм баласына булдыра алмаслык әйберне дә йөкләми. Аллаһның кануннарын авыр йөк итеп түгел, ә Аның рәхмәте итеп кабул итә белергә кирәк. Шул киң рәхмәтләрнең берсе ул - доган кабул булу. Күз алдыбызга гына китереп карыйк әле. Әгәр дә без һәр фарыз намазыбыздан соң, кулыбызны күтәреп, Аллаһтан кадерле әти-әниләребез, балаларыбыз, якыннарыбыз өчен саулык-сәламәтлек, дөньяларның тыныч булуын сорыйбыз икән, моның нинди начарлыгы бар? Аны болай гына да сорап була бит инде, диярсез. Ләкин Аллаһ чын ихластан сораган кешенекен генә кабул итә. Хәтта Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) шундый хәдисе бар: “Әгәр бер кеше, кулларын күтәреп, Аллаһтан чын күңеленнән дога кылып ни булса да сорый һәм бу вакытта аның керфекләре күз яше белән чылана икән, Аллаһ бәндәсенең соравын җавапсыз калдырырга оялыр”. Һәр фарыз намазыннан соң чын ихластан дога кылып сораучылар гына дога кабул булуның нинди зур бәхет икәнен аңлый ала. Шулай ук Аллаһ: “Миңа бер адым атласагыз, Мин сезгә йөгереп килермен”, - ди. Ә инде Аллаһка бер адым атлавыбыз ул - Аның әйткәннәрен үтәргә тырышып, Аңа якынаю. Ярдәмгә мохтаҗ булганда Аллаһтан дога кылып сорау һәм аның кабул итәчәгенә ышану - һәр мөселман өчен чиксез бәхет.

Ләкин кайвакыт сораган әйберең һаман күренми. Мондый очракта, Аллаһ догамны кабул итмәде, диючеләр бар. Тик алай күңелсезләнеп, төшенкелеккә бирелергә ярамый. Аллаһ - галәмнәр Раббысы безгә нәрсәнең файдалы, ә нәрсә зыянга икәнен яхшырак белүче. Шуңа да, догам кабул ителмәде, дип ашыгыч нәтиҗә чыгарыру дөрес түгел. Моның үз сере бар. Беренчедән, алда әйтелеп үткәнчә, димәк, без сорый торган әйбер, тормышыбызда хәерле түгел. Шуңа да Аллаһ безне аннан ерагайта. Икенчедән, ул доганың кабул булыр вакыты җитмәгән. Ягъни сораган әйберең бүген, иртәгә түгел, ә бер айдан чынга ашачак. Өченчедән, бәлки синең белән берәр күңелсезлек килеп чыгарга тиештер. Һәм кылган догаң әлеге күңелсезлек белән көрәшәдер. Бу дога сине хәвеф-хәтәрдән йолып кала, дигәнне аңлата. Һәм дога кабул булмауның тагын бер җитди сәбәбе бардыр. Кеше хәрам белән тукланганда аның догасы кабул булмый. Хәрам тулысынча организмнан чыксын өчен кырык көн көтәргә кирәк. Шуңа да, кылган догаларыбызның кабул булуын теләсәк, хәрам ризыктан ерак торыйк.

Аллаһ кушканча яши башлаган кеше күңелендә тынычлык барлыкка килүен сизә. Үзен чолгап алган проблемаларга карамастан, оптимистик рух, барысы да Аллаһтан, дип карау барлыкка килә. Дога кылып, Аллаһтан ярдәм сорый һәм барысы да яхшы булачагына ышана. Иң мөһиме, кеше тормышында асыл максат барлыкка килә - Аллаһның ризалыгына ирешү.

Асыл максат дигәннән, бер кыйсса сөйлим әле. Мисырда Зиннур Мисри исемле зур галим яшәгән. Аның егерме шәкерте булган. Галим шәкертләренә гел яңадан-яңа, файдалы дәресләр бирә икән. Үзе гел култык астына кыстырып бер китап йөрткән. Шәкерләр, остазлары бар гыйлемне нәкъ менә шушы китаптан ала, дип уйлаганнар. Һәм беркөнне галимнән китапны укырга рөхсәт сораганнар. Зиннур Мисри, мин үлгәч укырсыз, дип җавап биргән. Беркөнне Зиннур Мисри да вафат булган. Шәкертләре бик зур хирыслык белән, китапны укырга теләп, аның өчен тарткалаша башлаганнар. Араларыннан берсе: “Туктагыз әле, тарткалашмыйк, юкса ертырбыз. Әйдәгез, арабыздан берәү алып укысын, ә калганнар тыңлар”,- дигән. Китапны ачып карасалар - буп-буш. Шәкертләр аптырашып калган. “Ничек инде остазыбыз гомер буе буш китап күтәреп йөргән икән?” - дип гаҗәпләнгәннәр. Ә битләрен актара торгач, китапның нәкъ уртасыннан бер кечкенә генә кәгазь кисәге килеп чыга. Бу кәгазьдә түбәндәге сүзләр язылган була: “Ий кеше! Үткәнеңнән гыйбрәт ал, бүгенге көнеңнең кадерен бел, киләчәгеңә әзерлән (ягъни үлемеңә). Тормышыңда асыл максатыңны онытма, уңышка ирешерсең, бәхетле булырсың”. Бу сүзләргә тирән мәгънә салынганга күрә галим шул кечкенә генә кәгазь битен буш китап эченә салып күтәреп йөргән. Асыл максатын онытмасын өчен китапны үзеннән калдырмаган.

Намазга да, тыйганнардан тыелып, кушканнарны үтәп яшәүгә дә төрле кеше төрлечә карый. Әмма бер мөһим әйберне онытырга ярамый: Зиннур Мисри гомере буе саклаган кәгазь битендә язылганча, киләчәккә әзерләнергә кирәк. Ә ул ерак түгел. Моны барыбыз да яхшы аңлый. Галәмнәрнең Яратучысы булган Аллаһ белән очрашканда, күңелебез тыныч булсын өчен, Аның яратуына, ризалыгына бу дөньяда ук ирешергә кирәк. “Бәхет нәрсә ул?” - дип сораучыларга да шуны әйтәсе килә: бәхет ул - Аллаһның ризалыгына ирешү. Моннан да зур бәхет була алмый.

**Тимергали хәзрәт ЮЛДАШ**

# АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ

## БЕРНИГӘ ДӘ ОХШАМАГАН

“Аллаһыга охшаган һичнәрсә юк”. Бу сүзләр Коръәни-Кәримнең мөселманнарның ышанулары турындагы аятеннән алынган (“Киңәш” сүрәсе, 11 нче аять). Бу аятьтә ислам диненең төп нигез фикере бирелгән. Мөселманнар Аллаһы Тәгаләнең һичнәрсәгә дә охшамавына ышаналар. Бу раслау Аллаһының сурәтен киндергә ясау яки сынын әвәләү мөмкин түгеллеге фактын тану гына түгел, әлеге ышану тулаем, абсолют рәвештә кабул ителә. Аллаһы Тәгалә, гомумән, һичкемгә һәм һичнәрсәгә охшамаган.

“Күз алдыгызга ни генә китерсәгез дә, Аллаһы Тәгалә аңа охшамаган”.

Бу ышану исламдагы бераллалык белән монотеизм дип йөртелүче башка карашлар арасында зур аерма барлыкка китерә.

Ислам безне Аллаһының гәүдәсе булуына, Аның урын биләвенә яисә нинди дә булса (асмы-өсме, уңмы-сулмы) юнәлештә урнашуына, Аның өлешләре, үлчәме барлыгына һәм башка шундыйларга ышанырга ярамаганлыгына өйрәтә. Аллаһы Тәгалә барлыкка китергәннәргә хас тасвирламаларны Аның үзенә карата кулланып булмый. Ул тасвирламалар кимчелекле була, ә Аллаһы Тәгаләнең кимчелекләре юк.

Безне чолгап алган бар нәрсә дә алдан билгеләнеп куелган. Мәсәлән, дөньяда тере һәм тере булмаган һәр нәрсәнең төсе бар һәм без аларны аера алабыз. Әйләнә-тирәбездәге һәр нәрсә зәгыйфь, кимчелекле һәм без бу турыда сүз йөртә алабыз. Нәрсә дә булса хакында уйлаганда без аның үлчәме, җенесе, яше, холык сыйфатларын күз алдында тотабыз. Һәр нәрсәнең үзенчәлекләре һәм үлчәмнәре бар. “Ничек? Нинди?” дип сорарга мөмкин булган үлчәмнәр, чикләмәләр, сыйфатлар Аллаһы Тәгалә барлыкка китергән нәрсәләрнең тасвирламасы була. Чөнки параметрлары булган һәр нәрсәнең Яратучысы бар һәм Ул шушы параметрларны билгели дә инде. Аллаһы Тәгалә яраткан һәр затның барлык сыйфатламалары да конкретлаштырылган.

Менә, мисал өчен, Сафия исемле кызны алыйк. Аңа ничә яшь? Аңа биш яшь. Ул кемне ярата? Әнисен һәм әтисен. Нинди күркәм сыйфатларга ия бу кыз? Ул бик юмарт, бигрәк тә кәефе яхшы булса. Аның нинди кимчелекләре бар? Ул караңгылыктан курка. Боларның барысын да кем билгели? Боларны аны Барлыкка китерүче Аллаһы Тәгалә генә билгели ала.

Яратылган һәр нәрсәнең сыйфатлары билгеләмәгә мохтаҗ. Ләкин Аллаһы Тәгалә Үзе берәү тарафыннан да барлыкка китерелмәгән. Шуңа күрә Аның сыйфатларының чикләре юк. Барлыкка китерүче Үзе барлыкка китергән затларның сыйфатларыннан тамырдан аерылып тора. Шулай итеп, Аллаһы Тәгаләгә карата “Ничек? Нинди?” дип сорау куеп булмый, димәк, Ул кеше күз алдына китерә алырлык барлык нәрсәләрдән дә аерылып тора.

Аллаһы Тәгаләне күз алдына китерергә теләгән омтылышларны чикләргә, тыярга кирәк. Бу бигрәк тә балаларга кагыла. Сабыйлар уйлана-уйлана, Аллаһы Тәгаләнең барлыгына ышана башлап, намазга басканда, Аны күз алдына китерергә тырышып карыйлар. Югарыда китерелгән аять - ялгыш фикерләрдән саклаучы шифа ул.

**“Ислам турында сөйләшик” энциклопедиясеннән**

# БАШ АВЫРТКАНДА УКЫЛА ТОРГАН ДОГА

Аллаһ Рәсүле (с.г.в.) баш авыртканда бу доганы укырга киңәш иткән: **“Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Бисмилләһ иль-кәрим. Үә әгүзү билләһ-иль-газыйм мин шәрри күлли гыйркый нарин үә мин шәрри харр ин-нар”** (Рахман вә Рәхим булган Аллаһ исеме белән. Кәрим булган Аллаһ исеме белән. Һәртөрле авыруның зыяныннан һәм җәһәннәм уты зарарыннан бөек Аллаһка сыенам). (Мевахибуль-Ләддуния).

# КҮҢЕЛЛӘРЕ КОШ КҮҢЕЛЕ КЕБЕКЛӘР ҖӘННӘТКӘ КЕРЕР

**Әбу Һөрайра (Аллаһ аңардан риза булса иде) болай дип тапшырган: “Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде) әйткән: “Күңелләре кош күңеле кебек кешеләр җәннәткә керерләр”.**

“Шәрхел Мөслим” исемле хәдис шәрехнамәләре җыентыгында бу хәдис төрлечә аңлатыла. Берәүләр: “Хәдистә кошларныкы кебек йомшак күңелле кешеләр турында сүз бара”, - диләр. Икенче галимнәр: “Бу вакытта кошлар күңеленә салынган шүрләү, курку хисе күз алдында тотыла, чөнки кошлар җан ияләре арасында иң куркаклары (бу кешенең күңелендә кош күңелендәге кебек үк курку хисе бар, тик бу курку хисе - Аллаһтан курку, Аның ризалыгын алмый калудан, Аның дәһшәтеннән курку)”, - диләр. Ә кайберәүләрнең фикере буенча, бу хәдистә кошлар кебек Аллаһка сыгынучылар күз алдында тотыла.

Ничек кенә булмасын, кошлар, чыннан да, кешеләр үрнәк алырлык гүзәл сыйфатларга ия. Кошларда куралмаучанлык һәм үч алырга омтылу юк. Менә ни өчен күгәрчен - Җирдә тынычлык һәм татулык символына әйләнгән. Кошлар - сафлык гәүдәләнеше. Алда китерелгән хәдистәге кебек җәннәткә эләгергә тырышкан һәркем дә шундый югары рухи сыйфатларга ия булырга омтылырга тиеш. Андый югары рухи сыйфатларга ия кеше - күңеле саф, бар начарлыктан азат кеше.

Аллаһ кошларны күкләрдә очарга дип, нинди дер югарылык, биеклек, яктылык, изгелек ияләре итеп яраткан. Бәлки, Аллаһы Тәгалә безгә бу кыю һәм батыр кошлардан үрнәк алырга кушкандыр, алар үзләренең бик кечкенә булуларына карамастан, ерак араларны очып үтәләр, диңгез һәм океаннарны кичәләр, төрле киенлыкларны җиңеп чыгалар. Кошлар - иреклеләр, алар билгеле бер урынга бәйләп куелмаган. Алар Аллаһ рәхмәте белән иркенләп һавада очалар, үз тәкъдирләреннән канәгатьләр, бәхетлеләр.

Җәннәт әһелләренең күңелләре дә кошлар күңеле кебек. Алар - җитешсезлек һәм гөнаһлардан азатлар, аларның күңелләрен дөньявилык биләп алмаган. Кеше дә кошларга охшарга тырышырга тиеш, аның күңеле дөнья бозыклыкларыннан, явызлыклардан, куралмаучанлык һәм шикләрдән азат булырга тиеш. Кошның кечкенә генә йөрәге ачуланырга, ачу сакларга, үч алырга сәләтле түгел. Кешеләр дә үз ачуларын, ярсуларын контрольдә тотарга, бар урында да яхшылык күрергә, барысына да рәхмәтле булырга тырышырга, игелекле эшләрен риясыз эшләргә тиеш. Шул сыйфатларга ия булган кеше җәннәт әһеле булырга лаек.

**islam-today.ru**



# КАЙСЫ КӨНДӘ НИНДИ ГАМӘЛ КУЛАЙ?

**Якшәмбене** борынгылар ярдәм бирүче көн дип исәпләгәннәр. Бу көн дөнья көннәренең әүвәледер, яңарту көнедер. Ләкин бу көндә тырнак киссәң тормышыңның бәрәкәте китәр.

**Дүшәмбе** - Пәйгамбәребез галәйһиссәлам туган һәм үлгән көн. Җәбраил галәйһиссәлам Пәйгамбәр галәйһиссәламгә вәхи кылган көн. Ибраһим галәйһиссәлам Кәгъбәтулланы төзеп бетергән көн. Туган көнең дүшәмбе булмаганда бу көнне сәфәр чыгарга, тырнак кисәргә ярамый.

**Сишәмбе**. Аллаһы Тәгалә төрле хыянәтләрне сишәмбе көнне яратты. Бәхетсезлек, уңышсызлык көнедер. Аеруча бу - кан көне булып санала. Кабил Һабилне үтергән көн. Җирҗис, Зәкәрия һәм Яхъя пәйгамбәрне шушы көндә шәһит кылдылар. Шулай да бу көндә хастаханәгә барырга, тамырдан кан алдырырга ярый, әмма ләкин бу көндә кем дә кем тырнак киссә гаугадан, тавыштан котылмас.

**Чәршәмбе** - бик аз гына йомшаклык көне. Бу көндә күгәрченнән гайре җан ияләренең бәхетсезлек һәм шомлану көне. Гавиҗ, Фиргавен, Нәмруд, Гаад, Сәмүд кавеме бу көндә һәлак булалар, Юныс пәйгамбәрне балык йота, Ибраһим пәйгамбәрне Нәмруд ләгыйнь утка сала, Йосыф пәйгамбәр зинданга утыртыла. Бу көндә тырнак кисмәк бөтенләй ярамый.

**Пәнҗешәмбе**. Аллаһы Тәгалә нурны вә нәрны, җәннәтне вә җәһәннәмне шушы көндә яралткан. Шәригать әл-ислам тәгълиматы буенча бу көн Таләбул хаҗәт көне дип санала. Ягъни кылган догаларың кабуллыкка ирешә торган көн (ихлас күңелдән кылына торган булса).

Хәзрәти Рәсүл галәйһиссәлам бу көндә Мәккәне, Муса галәйһиссәлам Мисырны ачты. Йосыф галәйһиссәлам Мисырга падишаһ булды. Озак еллардан соң атасы Ягъкуп белән шушы көндә күрештеләр. Исмәгыйль галәйһиссәлам бу көндә дөньяга килде. Һәркем бу көннең икенде белән ахшам намазы арасында тырнак киссә, тәненнән рәнҗү китәр, шифа булыр.

**Җомга** - сәййүдул әййәм - атнаның иң изге көне, олуг бәйрәм көнедер. Аеруча бу көннәрдә җомга намазы, никах укыла. Адәм галәйһиссәлам белән Һәва анабыз да шушы көндә никахланган. Сөләйман галәйһиссәлам белән Бәлкыйс, Йосыф галәйһиссәлам белән Зөләйха, Муса галәйһиссәлам белән Сафура, Мөхәммәд галәйһиссәлам белән хәзрәти Хәдичә һәм хәзрәти Гайшә дә шушы көндә никахланган.

“Кыйссас Әл-Болгари” язмаларына караганда, Адәм галәйһиссәлам җомга көнне дөньяга килгән. Җомга көнне оҗмахка кергән, җомга көнне оҗмахтан чыккан. Туган көнең җомга булмаса, тырнак кисү өчен дә аеруча фазыйләтле көн булып санала. Әлбәттә, җомга намазы вакытында түгел.

**Шимбә** - сәбәт (сабат, шабат, шабаш - яһүд телендә “төгәлләнде”, “тәмам булды” мәгънәсен аңлата). Шимбә олуг хәйлә көнедер. Шулай ук ата-бабаларыбыз тарафыннан да сыналган шомлану, уңышсызлык китерә торган көн дип санала. Бу көндә Салих, Нух, Муса, Ибраһим, Гайсә, Мөхәммәд галәйһиссәламнәр бәхетсезлеккә дучар булган.

**“Мөбарәк кичәләрнең, айларның фазыйләтләре” китабыннан**

# ИЛАҺИ МОҢНЫ САКЛАРГА ЯЗСЫН

**Март аеның соңгы көннәрендә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте, Россия ислам институты, Бөтендөнья татар конгрессы “Илаһи моң” дип аталган рухи мирасыбыз ядкарьләренең беренче фестивален уздырды. Йомгаклау өлеше “Халыклар дуслыгы” йортында дин әһелләре, мәшһүр татар галимнәре, сәхнә осталары катнашында үтте.**

Тамашачыларны Татарстан мөфтие урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, РИИ ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин, мөфти урынбасары, Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт Сабиров, ТР Дәүләт Советы депутаты Фәрит Мифтахов, шулай ук Гамирҗан Дәүләтшин, Марсель Бакиров кебек атаклы галимнәр, Зөһрә Сәхәбиева, Миңгол Галиев, Гөлзадә Сафиуллина кебек сәхнә җәүһәрләре сәламләде.

Агымдагы елның Диния нәзарәте тарафыннан Дини гореф-гадәтләрне торгызу елы буларак үткәрелүен истә тотып, әлеге чара татар халкының дини һәм милли рухын, мирасын сәхнәдә тәкъдим итү булды. Әлеге чараның идея авторы һәм төп оештыручысы - Россия ислам институтының гуманитар фәннәр кафедрасы җитәкчесе Резеда Сафиуллина Әл-Әнси.





Фестивальгә кадәр Россия ислам институты тарафыннан “Татарларда ислам тарихы һәм ислам мәдәнияте нигезләре” дигән фәнни-тикшеренү эшләре һәм “Таян Аллага!” әдәби бәйгеләре, “Татар халкының рухи мирасы ядкарьләрен башкаручылар”, “Журналист буласым килә!” дип аталган конкурслар уздырылды.

Конкурсларга барлыгы 250 ләп гариза кабул ителде. Финалга 100 дән артык катнашучы үтте. Җиңүчеләр фестиваль тантанасында игълан ителде.

Фестивальнең өч сәгать дәвам иткән йомгаклау өлешендә сәхнәдә әйтелгән бәетләр, мөнәҗәтләр, татар мәкаме белән укылган Коръән аятьләре күңелләргә илаһи бер моң бирде. Менә шушы моң төрле буын кешеләрен һәм төрле өлкәләрдә динебезгә, халкыбызга хезмәт итүчеләрне берләштерде, рухыбызны баетты. Тантананы алып барган Татарстанның халык артисткасы, җәмәгать эшлеклесе Гөлзадә Сафиуллина һәм язучы, җәмәгать эшлеклесе Рабит Батулла да, сәхнә түренә күтәрелгән хөрмәткә лаек башка татар мәшһүрләре дә бу хакта кат-кат әйттеләр.

Гөлзадә ханым бу күркәм бәйрәмнең оештырылуына, үткәрелүенә зур өлеш керткән Диния нәзарәтенә рәхмәтен белдерде. “Мөфтиятебезгә, мөфтиебезгә зур рәхмәт. Әгәр мөфтиебез булышмаса, бәлки, рухи байлыгыбызга багышланган бу бәйрәм килеп тә чыкмас иде. Аллага шөкер, “Илаһи моң” фестивален бергәләп уздыра алдык. Алга таба да Аллаһы Тәгалә татар халкына бердәм булып, ныклы рухын саклап, моңын югалтмыйча яшәргә язсын”, - диде ул.





*Резеда Сафиуллина Әл-Әнси,*

***“Илаһи моң” фестиваленең идея авторы, төп оештыручысы:***



- Фестивальне оештырганда ук, бу - бәйрәм чарасы гына түгел, дәвамлы булырга тиеш, дип тотындык. Дүрт бәйгене бер фестиваль кысаларына җыюны алдан ук планлаштырмаган идек үзе. Мөнәҗәтләр конкурсы оештыру күптәнге ниятебез. Журналистлар конкурсына килгәндә, монысы замана таләбе. РИИда журналистика факультеты бар, ә ислам темасына яза торган абитуриентларны табу шактый катлаулы, конкурс үткәреп карыйк дип уйлаштык. Балаларның ислам тарихына кагылышлы фәнни-тикшеренү эшләре белән без инде күптәннән кызыксынып килөбез. Ә менә “Таян Аллага!” конкурсы ул - тарихлы конкурс. Аны фестивальгә кертеп, миңа калса, ике як та отты. Бу бәйгеләрнең һәркайсының нигезендә, гомумән иҗатның һәр төрендә шул илаһи моң ята бит инде. Конкурс эшләрен барлаганда шундый талантларны ачтык! Халкыбызның күңеле бай, илаһи моңнан мөлдерәмә булуын күреп сөендек.

## “ТАЯН АЛЛАГА!” КОНКУРСЫНА ЙОМГАК ЯСАЛДЫ

“Илаһи моң” фестивале кысаларында IV “Таян Аллага!” конкурсына йомгак ясалды. Конкурста катнашучыларга филология фәннәре докторы, Казан (Идел буе) университеты профессоры Фоат Галимуллин; “Казан утлары” журналының җаваплы сәркатибе, галим Рамил Ханнанов; “Ялкын” журналының баш редакторы, шагыйрә Йолдыз Миңнуллина, “Хузур” нәшрият йорты баш мөхәррире, “Шура” альманахының җаваплы сәркатибе Нияз Сабирҗанов бәя бирде.

Быелгы бәйгедә иллеләп артык автор җибәргән эш каралды. Конкурсны үткәрү өчен Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең уку-укыту һәм фән бүлеге белгече Айдар хәзрәт Карибуллин, РИИ мөгаллимәсе Резеда Сафиуллина зур өлеш кертте.

Белгәнебезчә, “Таян Аллага” конкурсын танылган дин әһеле Вәлиулла хәзрәт Якупов башлап җибәргән иде. Мәрхүм дин әһеле әлеге бәйге ярдәмендә бик күп яшь иҗатчыларны әсәрләрендә динне олыларга, мөселманнар тормышын яктыртуга әтәрде. Әлеге күркәм эш дәвам иттерелүе - бәйгенең туктап калмавы куанычлы хәл.

Быелгы бәйгенең олы бүләге - Гран-Прига Мингалиев Минневарис лаек булды. Проза номинациясендә 1 нче урын Гөлназ Нургатинага; 2 нче урын Райлә Галиевага, Миләүшә Галиуллинага; 3нче урын Гөлназ Массарова, Алия Әхмәтҗанова, Чулпан Гобәйдуллинага; “Шигърият” номинациясендә 1 нче урын Нурфия Халиковага, Дания Нәгыймуллинага; 2 нче урын Асия Корбангалиевага, Гөләндәм Галиева, Раилә Мансуровага; 3 нче урын Гөлфия Гайнетдинова, Газинур Нигъмәтҗанов, Зөмәрә Хәбибуллина, Зөлфия Миңнемуллинага бирелде. “Балалар иҗаты” номинациясендә Энҗе Әхмәтҗанова, Булат Насыйбуллин, Лилия Камаева, Алсу Хәлилова, Илзия Гавриловаҥың эшләре билгеләп үтелде.

**dumrt.ru сайтыннан**

# КАМИЛ хәзрәт СӘМИГУЛЛИН: ”Имамнарның һәм журналистларның уртак максаты - динне күтәрү”




**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте динебезгә дәгъват итүче, ислам кыйммәтләрен халыкка җиткерүче журналистларның “Каләм” конкурсына йомгак ясады.**



Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, аның урынбасарлары, “Татмедиа” басма һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы, РТ Президенты аппараты, Казан мэриясе вәкилләре, республика басмалары мөхәррирләре, журналистлары катнашында үтте.

Камил хәзрәт барлык журналистларга мөрәҗәгать итеп: “Безнең уртак максат бар. Имамнар да, журналистлар да динне күтәрү һәм исламның матурлыгын халыкка җиткерү өчен зур тырышлык куя. Бүген бергәләшеп “Каләм” конкурсына йомгак ясарга җыелдык. Ихластан динебезгә, мөселманнарга файда булсын дип эшләүче редакторларга, журналистларга Аллаһы Тәгаләнең әҗер-савaплары мулдан булсын, рәхмәтләре яусын. Алга таба да бергәләшеп ислам дөньясын ныгытырга насыйп әйләсен!”- диде.

Чара дәвамында “Ватаным Татарстан”, “Шәһри Казан”, “Казан утлары”, “Чын мирас” кебек саллы татар басмалары мөхәррирләре, журналистлары да хәзрәтләргә үз теләк-ниятләрен җиткерделәр. Матбугат чараларының Диния нәзарәте белән матур хезмәттәшлеге халкыбыз, динебез өчен бары файдага гына булуын билгеләп уздылар.

Быел алтынчы тапкыр оештырылган “Каләм” конкурсына барлыгы 67 эш тәкъдим ителгән иде. Алар арасында район газеталары, теле-радиокомпанияләре дә, республика күләмендә таралучы массакүләм мәгълүмат чаралары журналистлары хез-





мәтләре дә бар. Шулай ук Башкортстаннан һәм Удмуртиядән берәр иҗади хезмәт килеп ирешә.

**Мөселман массакүләм мәгълүмат чараларының VI “Каләм” конкурсы җиңүчеләре**

“Мөселман журналистикасына керткән хезмәте өчен” номинациясе:
**Альфред Мөхәммәтрәхимов**, "Яңа Гасыр" телерадиокомпаниясе;

“Мөселманнар турында иң яхшы телевизион сюжет”:
**Сәрия Хәбибуллина**, "Казан" телекомпаниясе,
**Ринат Әсхәдуллин**, “Яңа Гасыр” телерадиокомпаниясе;

“Иң яхшы интернет-ресурс”:
**Хатыйп Гәрәев**, "Татар-ислам.com",
**Мөршидә Кыямова** - “Интертат.ру”;

“Мөселманнар турында иң яхшы радиотапшыру”:
**Айгөл Әхмәтшина**, “Нократ” телерадиокомпаниясе, Мамадыш;

“Дөньяви ММЧда мөселманнар турында иң яхшы язма”:
**Алсу Хәсәнова**, “Ватаным Татарстан” газетасы,
**Алия Җамалиева**, “Татар-информ” матбугат агентлыгы;

“Дини ММЧда мөселманнар турында иң яхшы язма”:
**Йосыф Хуҗин**, Актаныш,
**Фирая Моратова**, Түбән Кама;

“Татарстанның иң яхшы мөселман басмасы”:
**“Мөселманнар” газетасы**, Бөгелмә;

“Дөньяви ММЧда ислам турында иң яхшы кушымта”:
“Шәһри Казан” газетасының **“Иманлы сүз”** кушымтасы;

“Мөселманнар турында иң яхшы телетапшыру”:
**“Рухи хәзинә”,** мөхәррире - **Мөршидә Җиһан**, “Татарстан” ДТРК;

“Гамәлгә куючыларның махсус номинациясе”:
Дини китаплар авторы **Василә Рәхимова**, күп еллар дини тематикага язган журналист **Диана Бачурина**;

“Каләм” конкурсы кысаларында Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең төрле өлкәләргә җаваплы бүлекләренең дә махсус бүләкләре журналистларга барып ирешә.

Диния нәзарәтенең әле узган ел гына ачылган “Хузур” нәшрият йорты дәгъват өлкәсендә зур эшчәнлек алып бара. Аның өч махсус бүләге, исламга дәгъват итүләрен зурлап, журналистлар **Римма Гатина**га (“Гаилә һәм мәктәп”), **Йолдыз Шәрапова**га (“Сабантуй”), **Чулпан Галиәхмәтова**га (“Болгар” радиосы) тапшырылды.

Диния нәзарәтенең бөтен тормыш-көнкүрешебез хәләл булсын өчен тырышлык куючы “Хәләл” комитетының махсус бүләкләре үзләренең хәләл хезмәтләре белән дин өчен тырышлык куючы журналистлар - **Рәшит Минһаҗ**га (“Ватаным Татарстан”) һәм **Райнур Шакиров**ка (“Азатлык”) бирелде.

Мөселманнарның хаҗ кылу теләгән тормышка ашыруда ярдәм итүче “ДУМ РТ ХАДЖ” оешмасы үзенең махсус бүләкләрен динебез кушканча яшәргә чакыручы, мөселманнарның бурычларын аңлатучы “Яңа Гасыр” телерадиокомпаниясенең “Нәсыйхәт” тапшыруын әзерләүчеләргә - **Ләйсирә Фазлыева**га, **Рифат Йосыпов**ка тапшырды.

**Айзирәк ГӘРӘЕВА**





# СӨЕМБИКӘ ЭНЕЛӘРЕ ҺӘМ СЕҢЕЛЛӘРЕ СЫНАТМАДЫ

**“Сөембикә энеләре һәм сеңелләре” дип аталучы дини-милли бәйге быел 17 тапкыр үткәрелде. Анда 4 яшьтән алып 18 яшькәчә биш йөзгә якын бала һәм яшүсмер катнашты. Әлеге бәйгедә катнашу өчен балалар Татарстанның төрле районнарыннан, шулай ук Самара, Ульяновск, Мордовия һәм Удмуртия Республикаларыннан да килгәннәр иде.**




Балалар Коръәнне яттан уку һәм ислам нигезләре гыйлеме буенча ярышты. Балалар шулай ук ислам тарихы һәм Татарстанның күренекле шәхесләре турындагы сорауларга да җаваплар бирде. Ярышларны быел да хатын-кызларның “Мөслимә” оешмасы рәисе Әлмира апа Әдиатуллина оештырды.

Бәйгене ачу тантанасында Татарстан мөфтие урынбасары Илдар хәзрәт Баязитов, Нияз хәзрәт Сабиров, Казан мэриясенең Телләр үсеше һәм иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлек бүлеге хезмәткәре Илгиз Сарманов, Казан шәһәре имам-мөхтәсибе Мансур хәзрәт Җәләлетдинов, Россия ислам институтының Коръәнхафизлар әзерләү үзәге җитәкчесе Ибраһим хәзрәт Сабиров, татар яшьләре форумы рәисе Тәбриз Яруллин һәм башка күренекле кунаклар катнашты.

Төрле яшь категорияләрендә көч сынашканнан соң быелгы бәйгенең җиңүчеләре билгеләнде. Казаннан Габдрахман Гомәров, Түбән Камадан Габдрахман Әүхәдиев, Казаннан Айнур Хәйруллин, Можгадан Кәримә Газизуллина, Яңа Чишмәдән Румия Кәримова, Казаннан Наилә Сабирова быелгы бәйгенең җиңүчеләре дип игълан ителде. Икенче, өченче урыннарны билгеләгәннән соң, Кол Гали исемендәге, Кол Шәриф, Шиһабетдин Мәрҗани, Һади һәм Садри Максудилар, Каюм Насыйри, Муса Бигиев, Галимҗан Баруди, Мөхлисә Бубый, Габдулла Тукай, Акмулла, Ризаэддин Фәхретдин, Хөсәен Фәезханов, Гатаулла һәм Сафа Баязитовлар, Хөснулла ахун Баһаветдин, Батырша, Әхмәт Тимер, Закир ишан Камалов Чистави, Хөсәен Әмирхан, Галиәсгар Камал, Мөхәммәтҗан Хөсәенов, Исмәгыйль Гаспралы, Зәйнулла ишан Рәсүлев, Әхмәтзәки Сафиуллин, Габделхак хәзрәт Саматов исемендәге бүләкләр дә үз ияләрен тапты.

Конкурста җиңүчеләрне татар галимнәре, тарихчылар, академиклар, язучылар, җырчылар һәм депутатлар котлады. Алар арасында Харис хәзрәт Салихҗан, Илһам ага Шакиров, Нурмөхәммәт Хисамов, Әнвәр Хәйри, Хатип Миңнегулов, Тәэминә Биктимерова, Зөһрә Сәхәбиева, Фаяз Хуҗин, Роберт Миңнуллин, Римзил Вәлиев, Искәндәр Гыйләҗев, Айдар Хәйретдинов, Айдар Хабутдинов, Фәйзелхак Ислаев, Фоат Рәфыйков һәм башкалар бар иде.



# ЧАЛЛЫДА ЯШЬ КОРЪӘН УКУЧЫЛАР БӘЙГЕСЕ УЗДЫ

**Чаллының Ак мәчетендә балаларның 19 нчы республикакүләм Коръән уку бәйгесе узды. Оештыручылары – ҮДО – Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте, Чаллы Мөхтәсибәте, “Ислам нуры” Дини-эшмәкәрлек Үзәге. Ул быел җөмһүриятебезнең 16 шәһәр-районыннан һәм Удмуртия Республикасыннан 171 яшь Коръән укучыны җәлеп итте.**




Аларның күпчелеген мөхтәсибәтләр оештырып алып килсә, арада әти-әниләре инициативасы белән генә килүче балалар да юк түгел иде. Быелгы бәйгегә шундый күренешләр хас булды: беренчедән, бәйгедә катнашучыларның яшәрә баруын билгеләргә кирәк. Быел 7 яшькә кадәрге төркемдә 32 бала көч сынашты. Аларның 12 сенә 4 кенә яшь иде. Ә бәйгенең иң яшь катнашучысы – Удмуртиянең Можга шәһәреннән Хәдичә Субаева әле 3 кенә яшен тутырган. Иң күп катнашучылар 10, 13 яшькә кадәрге төркемнәрдә булды. Ошбу төркемнәрдә үз осталыкларын сынаучылар арасында Коръәннең берничә җүзен яттан белүчеләр күп иде. Алар тәҗвид кагыйдәсен яхшы белүләрен дә күрсәттеләр. Шуңа күрә жюрига иң оста укучыларны билгеләү җиңел булмады. Чөнки балалар бер дәрәҗәдә диярлек укый. Шунлыктан бәхәсле парларны икенче мәртәбә укытырга да туры килде.

Быел да иң осталар булып Әлмәт, Түбән Кама вәкилләре танылды. Мәсәлән, 7 яшькә кадәрге төркемдә беренче урынны Әлмәттән әти-әнисе ярдәмендә дин гыйлемен үзләштерүче Газизә Минсабирова һәм Раян Хуҗин алдылар. 10 яшькә кадәргеләр арасында беренчелекне Түбән Камадан Шермәтов Габдулла, кызлар арасында шулай ук Түбән Камадан булган Гайшә Хәйбрахманова бүлештеләр. (Гайшәнең абыйлары Хәлил һәм Хәмзә балалар арасында танылган Коръән укучылар, Хәмзәгә, күп бәйгеләрнең җиңүчесе буларак, быелгы бәйгенең ачылышында Коръән уку тапшырылды).

13 яшькә кадәргеләр арасында Әлмәттән татар гимназиясе укучысы Асия Мөфлихунова, ә малайлар төркемендә Әлмәт районының Кол Шәриф авылыннан Габдулла Әүхәдиев иң югары балл җыйдылар. Ә 15 яшьлекләр төркемендә Балтачтан Әлинә Хәялова һәм Түбән Кама районының Шәңгәлче авылыннан Габдрахман Әүхәдиев иң көчлеләр булдылар. Шулай ук призлы 2, 3, 4, 5 нче урыннар билгеләнде. Беренче өч урынны алучыларга бәйге шартлары нигезендә дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр тапшырылды. Ә 4, 5 урынга лаек булучыларга истәлекле бүләкләр бирелде.

Бәйгене ҮДО – Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте вәкилләре – Коръәнне өйрәнү бүлеге башлыгы Илнур хәзрәт Хәйруллин һәм Казан мөселман көллияте директоры урынбасары Аймурат хәзрәт Хаҗиморатов, имам-мөхтәсибләр, Чаллы шәһәренең җәмәгатьчелек белән эшләү бүлеге башлыгы Рөстәм Галиуллин, күп санлы ата-аналар тамаша иттеләр.

Бәйге бергәлектә өйлә намазын уку һәм аш мәҗлесе белән тәгәлләнде.







***Рәсемнәрдә:***

*Илнур хәзрәт Хәйруллин 10 яшькә кадәрге төркемдә беренчелекне алган Шерметов Габдуллага бүләк тапшыра; Бәйгедән күренешләр.*

**Хәлил ШӘРИПОВ**

# "АК МӘЧЕТ"ТӘ ОЛЫ ҖЫЕН

**Бу язмада инде күркәм традициягә әверелеп баручы чара - Чаллының "Ак мәчет" мәдрәсәсендә оештырыла торган "Җәмгыять тормышын тотрыкландыруда ислам диненең әһәмияте" дип исемләнгән фәнни-гамәли конференция турындагы тәэсирләрем белән уртаклашасым килә.**

Коръән укылып, дога кылынганнан соң, тамашачылар игътибарына Ак мәчет мәхәлләсе һәм мәдрәсәсе тарихын яктыртучы видеоязма тәкъдим ителде. 1992 нче елдан үз эшчәнлеген башлап җибәргән мәхәллә шактый бай тарихка ия икән. Биредә хезмәт иткән ихлас, олы күңелле шәхесләр үз төбәкләрендә дин торгызылу процессына, ислам мәгарифе үсешенә саллы өлеш кертеп, бик күп файдалы эшләр башкарганнар. Мәхәлләдә яшәүче мөселманнарны бер җәмәгать итеп туплап, дини тормышны билгеле бер юнәлешкә салудан тыш, Ак мәчет хәзрәтләре халыкка дин белемен бирү эшен оештыруны да кайгырткannar: мәчет каршында барлык теләүчеләр өчен ислам нигезләрен үзләштерергә ярдәм итүче якшәмбе мәктәпләреннән тыш урта профессиональ дини белем бирүче көндезге мәдрәсә дә ачыла. Әүвәл анда берничә ел дәвамында хатын-кызлар гыйлем алса, соңрак (2000 нче елдан) биредә ир-егетләр генә укый башлый. Мәдрәсәнең кичке һәм читтән торып уку бүлекләрендә исә ир-атларга да, хатын-кызларга да белем алу мөмкинлеге тудырылган.

Шунысы әһәмиятле – мәчет-мәдрәсә җитәкчелеге безнең җирлеккә хас булмаган дини юнәлешләрнең зарарын, алардан ерак тору кирәклеген аңлатуны максатларның берсе итеп тәгаенләгән. Татарстан һәм Россиянең шактый күп төбәкләрендә дини оешмаларда хезмәт итүче "Ак мәчет" мәдрәсәсе шәкертләре шушы максатка бинаэн рәвештә үз эшчәнлекләрен хәнәфи мәзһәбе буенча алып бара. Бүген Татарстанда әлеге уку йортын тәмамлаган 3 казый, 4 район мөхтәсибе, 20ләп имам дин өлкәсендә нәтиҗәле хезмәт итә.

Шулай итеп, республикабызның дини мәгариф системасында аерым, күренекле урын тоткан мәдрәсә җирле традицияләрне саклауга, бердәмлеккә омтылуга йөз тотып үз эшчәнлеген оештырырга тырыша. Халыкка дин белеме бирү максатын тормышка уңышлы ашыру өчен биредә бөтен мөмкинлекләр дә бар: яхшы бинасы, төпле матди җирлеге, ә иң мөһиме - яхшы әзерлекле, югары дини белемгә ия булган мөгаллимнәре.

Мәчет-мәдрәсә коллективы белән 20 елга якын күренекле дин әһеле Рөстәм хәзрәт Шәйхевәли җитәкчелек итә. Ак мәчетнең имамы, мәдрәсәнең директоры булудан тыш, ул Кама төбәге казые, Татарстан Республикасы Диния нәзарәтенең президиум әгъзасы вазыйфаларын да башкара. Конференцияне әзерләү-оештыру эшендә дә Рөстәм хәзрәт башлап йөрүчеләрнең берсе иде. Әлеге чара башында чыгыш ясап, хәзрәт күпләрнең динне йола-гыйбадәт рәвешендә генә күз алдына китерүләрен әйтеп, фәнне дә өйрәнергә кирәклеген искәртеп узды. "Әгәр җәмгыятьтә фәнгә тиешле игътибар булмаса, ул җәмгыять таркалачак", - диде ул, һәм фәннең дөньяви һәм дини төрләргә бүленүен билгеләп узганнан соң, шундый фикере белән дә уртаклашты: "Әгәр дөньяви фәннәргә генә игътибар бирелсә, әдәп-әхлак бетәр, дини фәннәрне генә өстен итсәк, Көнбатыш илләренә бәйлелек хасил булуы ихтимал...".

Рөстәм хәзрәт фикерен куәтләп, Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин һөнәри дини уку йортларының төп максат-бурычы имамнар, мөгаллимнәр тәрбияләп чыгару белән генә чикләнмичә, төрле фәннәрне өйрәнеп, югары дәрәҗәләргә ирешкән зыялыларны әзерләүдән дә гыйбарәт булырга тиеш икәнен әйтте.

Фәнни-гамәли конференция эше 3 секциягә бүленеп алып барылды: Ислам һәм хәзерге заман актуаль проблемалары; Россия һәм дөньякүләм мөселман мәгарифе торышы; дин һәм фәннең үзара мөгамәләсе. Пленар утырышта Чаллы шәһәре башкарма комитеты вәкиле Р.Галиуллин, Татарстан мөфтие урынбасары Рөстәм хәзрәт Батров, филология фәннәре докторлары, профессорлар Мирфатыйх Зәкиев, Талгат Галиуллин, Марсель Бакировлар чыгыш ясадылар. Тарих фәннәре докторы, профессор Айдар Хабутдинов бүген Россиядә ислам таралуы һәм үсеше өчен бөтен мөмкинлекләр дә булуын искәртеп, татарларның үз диннәрен дөрес итеп, акыл-хикмәткә нигезләнеп тотарга тырышуларын әйтеп узды. "Үзбәкстанда ислам бар, ләкин анда авторитар режим; Төрекмәнстандагы мөселманнар да хакимият басымы астында ничә ел Коръән дәрәҗәсенә күтәреп "Рухнамә" укыдылар, татарлар исә мондый басымнан һәм ялгышлардан имин булдылар..." - диде А. Хабутдинов.

Секцияләрдә дә ихлас, тирән эчтәлекле, бик тә мәгънәле һәм файдалы чыгышлар күп булды. Сөйләүчеләрнең бердәм фикере буенча бүген илебездә динебезне тоту һәм тарату, Аллаһ Сүзен башкаларга җиткерү өчен искиткеч мөмкинлекләр бар, әмма шул ук вакытта бездә бозыклык, әхлаксызлык та зур тизлек белән тарала.

"Мөхәммәдия" мәдрәсәсе проректоры Зөлфәт хәзрәт Габдуллинның шактый күләмле докладында халкыбызның соңгы 100 ел дәвамында әхлаксызлана баруының сәбәпләрен анализлауга багышланган иде. Җыеп әйткәндә, Зөлфәт хәзрәт татарларның рухи түбәнлеккә төшүенә үз диненнән, аның әхлакый кыйммәтләреннән читләшү төп сәбәп-этәргеч булды, дип саный. "Ил күләмендә идеология алышынды, дини, әхлакый нигез югалганлыктан, халык нәрсә теләсә, шуны эшли башлады; телевидение аша үтереш, сүеш, фәхишәлек күренешләре иркен күрсәтелү нәтиҗәсендә үсеп килүче буын моны дөрес, табигый әдәп-әхлак нормасы буларак кабул итте. Дингә, милли гореф-гадәтләргә нигезләнгән элекке идеалларның күбесе юкка чыгарылды, шул сәбәпле халык исламда хәрам саналган спиртлы эчемлекләрне үз итте, ә бу исә милләттәшләребезнең әхлаксызлануына тагын бер җитди сәбәп булды...", - дип фикер-уйланулары белән уртаклашты Зөлфәт хәзрәт.

Чарада катнашучылар дин әһелләренең тырышлыгы, активлыгы, ихлас борчылып, хәлне яхшы якка үзгәртергә омтылуы бүген бик зур әһәмияткә ия, дигән фикерне тагын бер кат яңартып алдылар; үз төбәкләрендә башкарылган эш тәҗрибәләре белән уртаклашып, мәчетләр каршында укыту, мәдрәсәләр ачу, мәгълүмат чаралары аша халыкны агарту, кешеләрне вәгазь кичәләренә чакыру, балалар өчен җәйге лагерьлар оештыру кебек мөмкинлекләрне билгеләп үттеләр.


Универсаль, һәр заманга яраклы булган ислам кыйммәтләре низамы имин, тыныч, бәрәкәтле тормыш коруны, җәмгыятьнең һәм аерым шәхеснең бәхетле булуын максат итеп кешелеккә тәкъдим ителгән. Дөрестән дә, бу низам, җәмгыяви мөнәсәбәтләр формалаштыруда, илебезнең социаль мәсьәләләрен хәл итүдә гаять зур әһәмияткә ия, чөнки ислам дине тәкъдим итә торган канун-кагыйдәләр әхлаксызлык-бозыклыкка, төрле деструктив көчләргә каршы тору эшендә ярдәмче факторларның иң мөһимедер. "Ак мәчет" мәдрәсәсендә үткәрелгән конференциягә йомгак ясалганда да, оештыручылар бу хакта һәм дә динебезнең зур потенциалы, әле файдаланмыйча торган мөмкинлекләре шактый күп булуы турында аерым ассызыклап әйттеләр.

**Ришат КУРАМШИН,**
**Кукмара мәдрәсәсе мөдире**

# АВЫЛ МУЛЛАСЫНА АВЫЛДАШЛАРЫ НЫКЛЫК ТЕЛИ

**Татарстанда революциягә кадәр салынган мәчетләре сакланган авыллар әлләни күп түгел. Пучы шундый сирәк авылларның берсе. Бүгенге көндә авылда 28 метр биеклектәге манаралы, барлык уңайлыклары булган заманча мәчет эшләп килә.**

Казан - Уфа юлында урнашкан Актаныш районы Пучы авылының революциягә кадәр өч мәхәлләсе була. 1911 нче елны авыл уртасына агачтан салынган җамигъ мәчет динебез кысылган елларда да сакланып калды. 2007 нче елда исә әлеге тарихи мәчет янәшәсендә диярлек яңа мәчет калыкты. Яңа иман йортын халык Азат хаҗи мәчете дип йөртә. Юкка кушылмаган бу исем. Мәчет Пучыда туып үскән эшкуар Азат Фоат улы Абдуллин тырышлыгы, ярдәме белән, авылдашларына истәлек итеп төзелде. Азат әфәнде мәчетне үз ата-бабасы нигезенә салды. Бүгенге көндә дә Азат әфәнде мәчетне күз уңында тота. Шулай ук җирлектәге җитәкчеләр дә булышлык күрсәтеп торалар.



Мәчеттә 20 елдан артык авылдашларына иман нурын, динебез кыйммәтләрен җиткерүче Дамир Вәлиәхмәт улы Әхмәтов имамлык итә. Актаныш районы мөхтәсибе Руслан хәзрәт Мортазин сүзләренә караганда, Аллага шөкер, Пучы авылында күркәм генә дини эшчәнлек алып барыла. Биредә дин нигезләре укытыла, дини мәҗлесләр оештырыла. Әлбәттә, дини эшчәнлек иң беренче чиратта мәчет имамының һәм аның ярдәмчеләренең тырышлыгы белән алып барыла.


Быел март аенда мәчетнең имамы Дамир хәзрәткә 75 яшь тулды. Авылдашлары өлкән яшьтәге авыл мулласына нык-лык-саулык телиләр. Ислам динен таратуга зур тырышлык, дин юлында армый-талмый хезмәт күрсәткәне өчен Аллаһы Тәгалә үзе ярдәменнән ташламасын, диләр. Дамир хәзрәтнең ихластан башкарган эшләренә Аллаһы Сүбхәәнәһү вә Тәгаләнең рәхмәтләре булсын! Гаиләсенә, якыннарына да күңел тынычлыгы, тән сәламәтлеге, бәхет-шатлык, тәүфикъ-һидаять, озын гомерләр насыйп әйләсен!

# ИСЕМЕ ҖИСЕМЕНӘ ТУРЫ КИЛӘ

Бу сүзләрне Казанның Гаилә мәчете турында еш әйтәләр. Моның сере хәзрәтләрнең, мәчеттә хезмәт куючыларның ихласлыгында, җылы мөгамәләсендәдер. Социаль челтәрдә "Сөембикә" журналының баш редакторы урынбасары Гөлнур Сафиуллина болай дип язып куйган: "Кичә Гаилә мәчетенә кереп чыгарга туры килде. Дөресрәге, кереп кенә чыгабыз, дип уйлаган идек... Календарь кирәк иде, булмады. Әмма буш кул белән чыгуыбызны без сизмәдек тә бугай. Мин үзем мәчеттә шулай җылы каршы алуларын беренче тапкыр күрдем. Монда үзеңне ничек тотарга икәнен исебезгә төшерүче булмады. (Димәк, "син монда чит", димәделәр!) Эчкә узарга чакырдылар. "Икенче катка да менеп карагыз инде", – дип әйдәделәр. Әйтерсең, иң кадерле кунаклар без, әйтерсең, көтеп кенә торганнар! Балалар уйнап (!) йөри – тыйган кеше күрмәдем: үз өйләрендәмени. (Мәчеткә "Гаилә" дигән исемне юкка бирмәгәннәр бугай!) Чынлыкта, шулай булырга тиеш тә бит. Ишектән чыкканда, үземнең бу мәчеткә тагын килергә теләгәнемне аңладым. Сишәмбе көнне гаилә темасына багышланган лекцияләр укыйлар икән. Барам әле!"



# Рисаләи Газизә




“Хузур” нәшрият йорты Таҗеддин Ялчыголның “Рисаләи Газизә” китабын нәшер итте. Әсәрне басмага әзерләүче (гарәп графикасындагы текстларны укып, басмалар арасындагы аермалыкларны күрсәтеп, гамәлдәге язуга күчерүче, аңлашылмаган сүз-гыйбарәләрне һәм юлларны тәрҗемә итүче, тиешле шәрехләр бирүче) - танылган галим Хатыйп Йосыф углы Миңнегулов. Китап 3 мең данә тираж белән дөнья күрде.

Хатыйп ага кереш мәкаләсендә әсәр турында болай ди: “Таҗеддин Ялчыгол - халкыбыз тарихының, Рәсәй мәмләкәтенең шактый катлаулы һәм каршылыклы чорында яшәгән әдип. Милли һәм социаль изү, төрле сугышлар һәм баш күтәрүләр, мөселманнарны эзәрлекләү, көчләп чукындыру һәм урыслаштыру, фәкыйрьлек һәм ачлык - болар бар да шул чорга хас сыйфатлар. Шушындый кыен шартларда Таҗеддин Ялчыгол, үз туган теленнән тыш, гарәп, фарсы, госманлы һәм кайбер башка телләрне белә. Шәрык гыйлемнәрен һәм мәдәниятен үзләштерә. Аны, төрле тармакларда кылган гамәлләренә, язган китапларына карап, энциклопедик табигатьле галим дип тә атарга мөмкин. Ул, әлбәттә, барыннан да элек педагог. Әтисе васыятенә тугры калып, Таҗеддин Ялчыгол Мамадыш ягында да, Зәй төбәгендә дә “дәрес әйтә”, ярты гасырдан артык гомерен халыкны белемле, тәрбияле итүгә багышлый. Шул чорга хас булганча, аның мөгаллимлеге руханилык эшчәнлеге белән үрелеп бара. Әдип халыкта гасырлар буена тупланып килгән ислам рухын сакларга һәм ныгытырга омтыла. “Рисаләи Газизә” - Таҗеддин Ялчыгол иҗатында гына түгел, гомумән, Тукайгача чор татар әдәбияты тарихында мөһим ядкяр.

Шактый күләмле бу китап кульъязмаларда, XIX гасыр урталарыннан басма рәвештә гаять киң тарала. Казан университеты Фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кульъязмалар бүлегендә генә дә аның 40 тан артык тулы һәм өлешчә нөсхәләре бар. “Рисаләи Газизә” - әдәбиятны, динне, телне, мәгарифне, гореф-гадәтләрне, гыйлем тарихын тикшерүдә мөһим чыганак.

Таҗеддин Ялчыголның "Рисаләи Газизә" китабы Татарстан Республикасы Президенты Аппараты җитәкчесе Сәфәров Әсгать Әхмәт улының матди ярдәме белән басылды. Китапның кереш өлешендә Әсгать әфәндедең: " Татарлар элек-электән үткәнне нәсел җебе аша барлаган. Шуңа да рухи мирасны буыннан - буынга әманәт итеп тапшыра килү бурычы сакланган.Таҗеддин Ялчыголның яңа китабын бастыру минем өчен менә шул бурычны үтәү дә, бабам рухын сөендерергә омтылу да булып тора", - дигән сүзләре китерелә.

# Шәех Хәбибулла кыйссасы

Килдек үзебезнең максатыбызга. Кыйссаларда шулай әйтелә ки, һиҗрәтнең мең дә йөзенче елында (ягъни 1689 нчы елда) Бохара халкы иман вә гыйбадәткә ялкау булып, бидгать (ярамаган) эшләргә чумдылар. Кыскасы, болар, тугыз ел начар вә бидгать эшләр артыннан йөреп, диннең асылларын югалтуга якынайганнар иде. Бохарада бер углан Ристан дигән базарда кавын, карбыз сатып йөри иде. Ул углан мондый бер фикердә икән: бу данлыклы Бохара шәһәре шулкадәр бозыклык һәм азгынлык белән тулган ки, әүлияләр әләме юкка чыкты. Йа Рабби, зинһар, бу бәндәңне газиз әйләп, боларга әмеремәгъруф (үгет-нәсыйхәт, вәгазь) итәрлек кадәрле гыйлем бирсәң, диде. Хак Тәгалә хәзрәтенә зар-зар елады.

Кыскасы, бер чәршәмбе көнне Хуҗа Бәһаведдин* әүлиянең каберен зиярәт итте. Анда да Хак Тәгалә хәзрәтенә күп догалар кылды. Моннан соң йокы басты. Йокыга китте. Төшендә бу сыйфатта Хуҗа Бәһаведдинне күрде: урта буйлы, күк (зәңгәр) күзле, кызыл сакаллы. Диде ки: “Әй, бәгърем, син Сәмәркандка бар, анда бер сыер көтүчесе булыр. Минем мөридләремнән. Син аннан белем ал. Соңыннан килеп, бу Бохараны яхшы эшкә дәгъвәт ит (өндә)”, - диде.

Шулай итеп, бу углан йокысыннан уянып, шунда ук Сәмәркандка юнәлде. Бер көн Сәмәркандка барып җитте. Сыер көтүчесен күрде. Исеме Әндәрҗан Суфый иде. Мөридләре күп иде. Бу углан Хәбибулла һәм Әндәрҗан хәзрәтләренә чын ихластан мөрид булды. Күп вакыт анда аң-белем алды.

Кыскасы, Шәех Әндәрҗан көннәрдән бер көн әйтте: “Кайсыгыз Бохарага барып гыйлем өйрәтәсез? Ул Бохара халкы азгын булды. Әүлияләр әләме юкка чыкты”. Мөридләр һичберсе җавап бирмәде, һәм шуннан соң Шәех хәзрәтләре Хәбибуллага карап әйтте: “Бохарага син бар, Аларны мөрид әйлә. Мин сиңа рөхсәт бирдем”, - диде.

Бу Хәбибулла ул вакытта егерме яшендә иде. Хәбибулла әйтте: “Йә Шәех, әйе, синең сүзеңнән чыгу - көферлектер. Ләкин сез бер мәҗлестә шулай дигән идегез: “Шәех булган кешегә дүрт нәрсә кирәк: беренчесе - зирәклек, икенчесе - сөйләм осталыгы, өченчесе - тиешле яшь, дүртенчесе - мал кирәк... Ләкин боларның һичберсе дә миндә юк”, - диде. Зирәк булмыйча, мөридләр тәрбияләп булмас. Сөйли белмичә, гыйльме заһирга** җавап биреп булмас. Өлкән яшь шуның өчен кирәк: бик яшь булса, халык аны түбәнсетер. Мал халыктан сорамас өчен кирәк.

Һәм Шәех, бу сүзне ишеткәч, уйга чумды. Бер сәгатьтән соң торып җавап бирде: “Әй углан, бар. Юлда һәрберсе сиңа хасыйл булыр (табарсың)”, - диде. Шуннан соң бу Хәбибулла, Аллаһу Тәгаләгә тапшырып, хәзрәте Шәехне күңеленә алып китте. Бохарага җиткәндә, Аллаһу Тәгалә аны кырык яшьлек кеше кыяфәтенә әйләндерде, илаһият гыйлеме һәм гыйльме кимийа (могҗиза кылу, химия белеме) бирде. Халыкка һич ихтыяҗы калмады. Бохарага килеп керде, бер иске кибеткә кереп утырды. Кешеләрдә ярамаган эшләр күрсә, тиешле эшләрне эшләргә өндәү вә тыелган эшләрдән тыю белән шөгыльләнде һәм шул кибет янындагы балаларга сабак-дәрес бирде. Базардагы сәүдәгәрләрнең күбесе мөрид булды. Бу вакыйга һәм аның гыйлеме Бохарада мәшһүр була башлады.

Кыскасы, Бохараның ханы, үзенең галимнәрен ашка чакырып, Пәйгамбәр хәдисләрен укыдылар, күп гыйбрәтләр алдылар. Галимнәр арасыннан берсе әйтте: “Йә падишаһ, гомерең озын булсын! Безнең Бохарага бер ялганчы килеп, үзен олуг шәех санап, мөридләрне тәрбияли икән. Инде син, тагын бер мәҗлес җыйганда, аны да чакыр, безне дә чакыр. Без аннан дингә ышану мәсьәләләрен, Хак Тәгаләнең берлеге турында сорарбыз. Әгәр аның дини мәсьәләләрдән хәбәре булмаса, шәһәрдән куарбыз”, - диделәр. Шулай итеп, болар, киңәшеп, бу фикергә килделәр, шаһ мәҗлесеннән чыгып киттеләр.

Кыскасы, көннәрдән бер көн шаһ мәҗлес җыйды. Галимнәрне чакырды һәм дамелла Хәбибулланы да шунда чакыртты. Бу Хәбибулланың бер һинди ишәге бар иде. Аңа менде, падишаһ мәҗлесенә барды. Кереп, галимнәр арасына утырды. Хәл-әхвәл сораштылар. Аннан соң галимнәрдән берәү әйтте: “Йә дамелла Хәбибулла, Ходаны ничек танырсың? Һәм ничә сыйфат белән белерсең?” - диде. Шунда ук Хәбибулла җавап бирде: “Әгәр Ходаның сыйфатын вә берлеген белми торган булсагыз әйтегез. Әгәр имтихан өчен сорый икәнсез, монафикълык (икейөзлелек) уртасында сез”, - дигәч, галимнәр тындылар, һичберсе каршы сүз әйтмәде. Аннан соң дамелла Хәбибулла әйтте: “Мин Коръәндә сурәи Йосыфны таба алмыйм”, - диде. Шул чак галимнәр арасыннан берсе әйтте: “Мин хәзер сурәи Йосыфтан сабак өйрәттем, мин табармын”, - диде. Иншә Аллаһ Тәгалә димичә, “Коръән Шәриф”не кулына алды, кәгазьләрне актарды, тапмады. Аннан соң тагын берсе алды. Ул да тапмады. Болар барысы да аптырап калдылар. Ахыр чиктә бу дамелла Хәбибулла Коръәнне кулына алды. “Бисмилләһир-рахманиррахим” дип ачты, сурәи Йосыфны күрсәтте. Бу эштән таң-гаҗәп калдылар. Шәех Хәбибулла, аннан чыгып, үз эшенә китте. Падишаһ калган галимнәргә әйтте: “Сез бу галимне дошман күрмәгез, чөнки сезгә кәрамәт (могҗиза) күрсәтте. Сез белдегезме?” - диде. Барчалары гаҗәпкә калдылар, аптырадылар. Мәҗлестән чыгып киттеләр.

Кыскасы, көннәрдән бер көн шаһ тагын бер мәҗлес корды, галимнәрне чакырды. Барысы да килделәр. Шәех Хәбибулла да шунда иде. Баягы ишәгенә менеп килгән иде. Утырдылар. Тәгамне (ризыкны) галимнәр алдына китерделәр. Падишаһ әйтте: “Авыз итегез, ашагыз!” - диде. Һичберсе кул сузмады. “Син әүвәл кул суз. Син беренче кул суз!” - дип, бер-берсенә әйтеп, бер сәгать чамасы тордылар. Әмма шаһ боларны күреп әйтте: “Йә галимнәр, ни өчен ризыкка кул сузмыйсыз, тәгам хәләлдер”, - диде. Моннан соң араларыннан бер мелла - Нияз Чукмакый исемлесе “әфәнде, бисмиллаһ”, диеп тәгамгә кул сузды. Аның артыннан барча галимнәр кул суздылар. Бу Шәех Хәбибулла кул сузмады, тик торды. Падишаһ әйтте: “Йә дамелла Хәбибулла, ни өчен кул сузмыйсың?” - диде. Хәбибулла әйтте: “Тәгамең хәрамдыр, галимнәрең фасикълардыр (бозыклардыр), - диде. - Төн-көн хәрам ашап, күңелләреннән хикмәт нуры качкан”, - диде. Галимнәр җавап биреп әйттеләр: “Безгә шәригать тыштан карарга кушты. Без бу шаһның ризыгында хәрам нәрсә күрмәдек. Син күрмичә, ничек хәрам дип фәтва бирәсең?” - дип галимнәр арасында гауга, җәнҗал күп булды.

Хәтта Шәех Хәбибулланы якалый башладылар. Шәех Хәбибулла әйтте: “Сабыр әйләгез, чөнки падишаһның, су алып, аш пешерә торган коесына бер кәнизәк (хезмәтче хатын) тавык үтереп ташлаган. Өч көн булды. Шаһның кырыслыгыннан куркып әйтми, - диде. - Тәҗрибә өчен шул коеның суын алып, минем ишәгемә китерсеннәр - эчмәс. - диде. - Әгәр гайре (башка) коедан алып китерсәгез, эчеп туймас”, - диде. Аннан соң шулай иттеләр. Шул коедан алып китерделәр, ишәк алдына куйдылар. Пошкырып эчмәс булды, аягы белән суны тибеп түкте. Башка коедан китереп, ишәк алдына куйдылар, туйганчы эчте. Шәех Хәбибулла әйтте: “Минем ишәгем бу галимнәрдән галимрәк икән”, - диде. Падишаһ һәм галимнәр барчалары хәйран калдылар. Моннан соң шаһы хәзрәт хезмәтче кыздан сорады: “Коега тавык үтереп ташладыңмы?” - дигәч, “Әйе, бардыр”, - диде. Шуннан соң коедан тавыкны чыгардылар һәм Шәех Хәбибулла могҗизасын таныдылар, чын әүлия дип мөридлеккә керделәр. Әүвәл шаһ керде, аннары барча галимнәр керделәр.

Бохарада никадәр бидгать (бозык) эшләр булса, барчасы тыелды, бетерелде. Бохара халкының төн-көн тәүфыйклары артты, күп кеше аңа иярделәр, шөһрәте илдән-илгә таралды.

*Хуҗа Бәһаведдин - Мөхәммәд Нәкышбәнди (1314-1389) - Урта Азиядә яшәгән атаклы суфый.

**Гыйльме заһир - тышкы, дөнья турындагы тәгълимат.

**Исламның бер баганасы булган хаҗ кылу кем өчен фарыз? Кемнәр аннан азат ителә? Көтелмәгән өстәмә кыенлыклар килеп чыкмасын өчен хаҗилар нәрсәгә игътибар итәргә тиеш? Бүгенге әңгәмәбездә "ДУМ РТ ХАДЖ"ның медицина бүлеге белгече Рамил ХИСАМОВ шушы сорауларга медицина күзлегеннән чыгып җавап бирә.**



## ТАТАРСТАННЫҢ ХАҖ КВОТАСЫ - 1800

Быел изге хаҗ сәфәренә Татарстаннан 1800 кеше бара ала. Бу хакта Мәскәүдә Федерация Советында үткәрелгән 2014 нче елгы хаҗ сезонын оештыруга багышланган җыелышта мәгълүм булды. Әлеге чарада Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, "ДУМ РТ ХАДЖ" программасы җитәкчесе Хәбибулла Нәфисуллин катнашты.

Россия күләмендә хаҗга барлыгы 16400 квота каралган. Узган ел бу сан 20500 иде. Квоталарны кыскарту Согуд Гарәбстаны хөкүмәтенең Мәккәдә алып барган төзекләндерү эшләренә бәйле. Әлеге кыскартулар барлык илләргә дә кагыла. Шул ук вакытта Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте татарстанлылар өчен квотаны арттыруга иреште, узган ел ул 1200 генә иде.

# *ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗ (С.Г.В.) ХАҖНЫ ЯШЬ ЧАКТА КЫЛЫРГА КУШКАН*

**– Рамил әфәнде, Сез нинди авырулары булган кешеләргә хаҗ сәфәренә бармаска тәкъдим итәсез - шул исемлекне барлыйк әле.**

– Болар - инсулиннан бәйле шикәр авырулы кешеләр; психик авырулар; туберкулез белән авыручылар һәм йөкле хатыннар. Булачак хаҗилар, минем андый авыруларым юк, мин йөкле түгелмен, дип кул куеп, гарантия бирә. Әгәр дә инде авыру булуга карамастан юлга чыгып, хаҗда шул авыртуы кискенләшеп китсә, компания аның өчен җаваплы түгел, ул хаҗи үз юлы белән кайтырга тиеш була. Бу Согуд Гарәбстанының Россиядәге илчелеге таләбе дә. Андый диагноз куелган кешегә хаҗ кылу фарыз түгел. Инде хаҗ кылырга теләге бик зур, акчасы да бар икән, туганын я күршесен җибәрә ала.

Хаҗиларны сәфәргә без алдан ук бик яхшылап әзерләргә тырышабыз. Лекцияләр укыйбыз, әңгәмәләр үткәрәбез. Махсус медицина белешмәлеге чыгардык. Ничек киенергә, аяк киемен ничек сайларга, нинди дарулар алырга - анда барысы да бәйнә-бәйнә язылган.

**– Хаҗилар үзләре белән дарулар да алырга тиешме?**

– Һәркем үзе еш куллана торган иң кирәкле даруларны гына ала. Безнең компания бик зур күләмдә кирәкле медикаментлар белән тәэмин ителгән. Узган ел ул 800 мең сумлык булды. Татарстан хөкүмәтенә, Татарстанның Сәламәтлек саклау министрлыгына рәхмәт; медикаментлар, табиблар белән тәэмин итеп, менә инде ун ел буе алар Татарстан Диния нәзарәтенә, мөселманнарыбызга зур булышлык күрсәтәләр. Россиядә башка мондый төбәк юк. Узган ел хаҗиларны 12 табиб озатып йөрде. Быел квота арту сәбәпле 15 табиб сорарга дип торабыз.

Без һәр очкычка берәр табибны билгеләп куябыз. Гарәбстанга барып төшүгә медпунктны ачабыз. Узган ел дүрт кунакханәнең икесендә медпункт эшләде, тәүлек буе икешәр табиб кизү торды. Ике кардиограф, глюкометрлар (анда ризык бик баллы, сәламәт кешенең дә шикәре күтәрелеп китәргә мөмкин), медикаментлар салынган махсус сумкалар - беренчел ярдәмне күрсәтү өчен барлык кирәкле әйберләр бар. Хаҗиларыбыз кая барса да, аларны табиблар озатып йөри.

**– Шайтанга таш атарга да табиблар сумка күтәреп барамы?**

– Әлбәттә. Медикаменты булмый икән ул нинди табиб ди! Иң авыры - Минада. Хаҗилар анда җиде көн буе чатырларда тора. Таш атарга бара алмаучыларны автобус белән кунакханәгә кайтарып куябыз, алар өчен, алар исеменнән, ташны башка кеше ата ала. Хаҗның беренчел нигезе – Гарәфәт тавында тору. Шунда тору өчен "ашыгыч ярдәм" машиналарында хәтта реанимациядәге (үз аңында булган) авыруларны да алып киләләр. Узган ел безнең бер хаҗиебез больницага эләккән иде, аны да Гарәфәгә китерделәр.

**– Ә больницада яткан өчен кем түли?**

– Клиникага ятарга туры килә икән, безнең белән эшләүче иминиятләштерү компаниясе түли. Ә хаҗ вакытында исә медицина тулаем бушлай, бу - Согуд Гарәбстанының хаҗиларга бүләге. Хаҗилар үз сәламәтлекләренә битараф булмасыннар иде. Юкса өчәр мәртәбә инфаркт, инсульт кичергәннәр бара бит хаҗга. Анда кырык градус эсселек, кайсыларының кан басымы күтәрелә, йөрәкләре авырта башлый. Алла сакласын, ул-бу булып куюы бар...

**– Андый хәлләр дә булгалыймы?**

– Хәтерем ялгышмаса, 1999 нчы елда бер бабай инсульттан үлеп китте, бәдрәфтән үзем алып чыктым. Дөньяныкын белеп булмый, шуңа күрә юлга чыгар алдыннан хаҗи үлеп китсә, шунда җирләргәме, әллә туган илгә алып кайтыргамы, дигән мәсьәләне дә күтәрәбез. Үзе Согуд Гарәбстанында җирләргә рөхсәт биреп кул куя икән, туганнары бездән берни дә таләп итә алмый. Кул куймый икән, аны алып кайтуны компания үз өстенә ала.

**– Хаҗ кылганда аякларга бик авырга туры килә, көненә җәяүләп 18-22 шәр чакрым ара үтелә, дип ишеткәнем бар. Ә бит анда күбрәк өлкән яшьтәге кешеләр бара...**

– Әйе, кайбер хаҗиларның аяклары бик авырта башлый. Әмма табиблар да, җитәкчеләр дә аларны тартып йөри алмый, аларның үз вазифасы бар. Аяклары авырта, йөри алмый икән, туганыннанмы, дустыннанмы шунда арбага (коляскага) утыртып йөртүләрен сорарга тиеш була. Анда арбалар безнең акча белән 3-4 мең сум гына тора. Тар-ып йөрүче кешесе юк икән, кемнедер ялларга туры киләчәк. Кеше хаҗга үз хәлен үзе белеп, яхшылап тикшеренеп барырга тиеш. Монда, сәфәргә чыкканчы, ул өй тирәсендә бик сәламәт күренә, ә тегендә хаҗга баргач бөтенләй хәлсезләнүе мөмкин. Аннары, мине монда алып килдегез, әйдәгез, хәзер ничек телисез шулай йөртегез, дип аяк терәп таләп итүчеләр дә булгалый. Хаҗга бару - күрше авылга Җәмилә әбинең хәлен белергә бару түгел ул. Пәйгамбәребез (с.г.в.), хаҗны яшь чагында кылыгыз, дигән. Кабатлап әйтәм: үзе бара алмаган кеше, үз исеменнән туганын, дустын, күршесен җибәрә ала. Шулай итеп фарыз булган хаҗ гамәле аның өстеннән төшә, ә барган кешегә инде әҗер савабы була.


**– Ризык мәсьәләсендә хаҗилар бик талымлы түгелме? Безнең татар кухнясы андагыдан шактый аерыла бит.**

– Анда безнең үз ашханәбез бар. Хаҗиларны көненә өч тапкыр ашаталар. Ризыклар артык ачы, тозлы-борычлы түгел, төрек кухнясына якын. Поварларның документлары тәртиптәмеюкмы - башта шуны тикшерәбез, аларның ризыкны ничек әзерләгәннәрен, савыт-сабаның чисталыгын - барын да күзәтеп, контрольдә тотабыз. Көтелмәгән күңелсезлекләр килеп чыкмасын дисәң, урамда сатылган ризыкны ашамаска кирәк, чөнки анда читтән килгән кешеләр - ялланган пешекчеләр әзерли, алар санитария кагыйдәләрен саклап тормый.

Соңгы елларда хаҗиларның әзерлек, аң дәрәҗәләре шактый үсте. Без тараткан белешмәлекләрне укып, киңәшләребезгә колак салсалар, үз эмоцияләренә хуҗа була алырлар, хаҗ гамәлен җиренә җиткереп үтәрләр, иншә Алла. Ә тарткалашу юктан гына да чыгарга мөмкин бит ул, чөнки шайтан анда тәүлегенә 25 сәгать эшли. Мәсәлән, 70 яшьлек карт белән яшь-яшь егет бер бүлмәгә туры килсә, яшенә эссе - ул кондиционерны кабызып куя, ә олы яшьтәгесенә салкын - ул барып сүндерә. Шулай кондиционерны бер кабызып-бер сүндерә торгач тавыш чыга. Хаҗга бит кеше иңнәрен баскан гөнаһларыннан арынырга бара. Ә Иблискә бу кулай түгел, ул 40-50 ел буе әлеге кешене җәһәннәмгә олактырырга тырышкан, ә бу бер ай эчендә гөнаһтан арынырга мөмкин. Үзеңне кулда тота алмасаң, телеңә хуҗа булмасаң, гөнаһтан арыну түгел, өстәп тә алып кайтырга мөмкинсең әле, анда гөнаһ икеләтә языла. Пәйгамбәребез (с.г.в.) заманында хаҗга авызларына таш кабып барганнар. Ул ташны ашаганда-эчкәндә, тәһарәт алганда һәм ятканда гына авызларыннан алганнар, менә ничек итеп телләрен гөнаһтан саклаганнар...

**– Рамил әфәнде, Сезне тыңлагач, бик күпләр, мин әзер түгел икән әле, дип хаҗны кичектерү ягын карамас микән?**

– Әзер түгелмен дигәннән, монысы да шайтан эше. Акча да бар, сәламәтлек тә ярыйсы, ә шайтан һаман, син әзер түгел, дип котыртып тора. Берзаман Газраил килер, аңа акчаң да, сәламәтлегең дә кирәкмәс, аны синең әзер булу-булмавың кызыксындырмас...




**Әңгәмәдәш – Нәүбәһар КӘБИРОВА**

# КАЗЫЙ КИҢӘШЕ

*"Әссәламе галәйкүм! Мин урын өстендә генә ята торган авыру, инвалидмын, шунлыктан мәчеткә йөри алмыйм. Зинһар өчен, минем сорауларыма газета аша җавап бирегез.*

*1.Берәр кеше турында аның кимчелекләрен сөйләгәнне тыңлаган, үзе дә кушылып сөйләгән кеше тәүбә итеп, ул кешедән гафу үтенергә теләсә: "Кайчан да булса мин сине сүзләрем яки гамәлем белән рәнҗеткән булсам гафу ит", - дию җитәме? Аллаһ моны кабул итәр микән? Әллә кайчан, ничек рәнҗеткәнне әйтергә кирәкме?*

*2. Саклык кенәгәсендә 12 мең сум акчасы булган кеше корбан чалырга тиеш дип ишеттем, шул дөресме? Әгәр өч пенсионердан торган гаиләнең 48 мең сум акчасы булса, аларга 3 сарык чалыргамы, әллә гаиләгә берәү дә җитәме? Бу гаиләдә ике инвалид, аларга сәдака итеп корбан ите китерәләр, аны алырга ярыймы? Саклык кенәгәләрендә 48 мең сум акчалары булгач, бу алар өстенә гөнаһ булып язылмас микән? Зәкят, гошер сәдакалары алу да ярамый микән? Сездән җавап көтеп, Казаннан Роза".*



Газета укучыбызның сорауларына Татарстанның баш казые ярдәмчесе **Рөстәм хәзрәт ВӘЛИУЛЛИН** җавап бирә:

1. Тәүбә итеп, чын күңелдән гафу үтенсә, шул җитә.

2. Нинди генә бай булсалар да, бер гаиләдән бер корбан чалына. Корбан чалу сезгә важиб түгел, чөнки сез сәдака әһелләре. Мөмкинчелегегез булып, чалдырсагыз, савабы булыр. Иншә Алла.

3.Бер дә шикләнмичә сәдакаларын да, гошерләрен дә алыгыз. Имин булыгыз.

# ӨЙЛӘНЕШЕГЕЗ, ҮРЧЕГЕЗ...

**Бүгенге көндә аборт (йөклелекне өзү) очраклары ешайды. Элек ислам дөньясында андый фактлар гадәттән тыш күренеш булган.**



Элек мөслимәләр баланың дөньяга килүен шатланып көткәннәр, ә күп балалы аналар аеруча хөрмәткә ия булганнар. Ләкин хәзерге вакытта кайберәүләр өчен баланың дөньяга килүе, йомшак итеп әйткәндә дә, шатлык түгел. Күпләр авырга узу белән аборт ясату турында уйлана башлый.

Без күтәргән мәсьәлә хәзерге заман өчен бик тә актуаль, кайберәүләр хәтта, аборт ясау - рөхсәт ителгән яки хупланмаган гамәл, дип тә сөйли башладылар. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең бер хәдисен искә төшерик әле. Ул: "Өйләнегез һәм кияүгә чыгыгыз, үрчегез, күбәегез, чөнки мин бу вакытта сезнең белән башка өммәтләр каршында горурланырмын", - дигән (Нәсаинең Сөннәнендә китерелә).

Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) безгә өйләнергә, балалар тудырырга һәм өммәтенең санын арттырырга васыять итеп калдырган һәм шул сәбәпле безнең белән башка өммәтләр каршында горурланырмын дигән.

Хисап көнендә иң беренче итеп кубарылачак кеше - безнең Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам. Кыямәт көнне аңа төрле өммәтләрне күрсәтерләр: бер-ике генә кешедән торган өммәтне дә, зур өммәтне дә. Ул: "Шулмы инде минем өммәтем?" - дип сорар. Җәбраил (аңа Аллаһның сәламе булса иде): "Бу - Муса (аңа Аллаһның сәламе булса иде) өммәте", - дияр. Аңа (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) башы-ахыры күренмәгән бик тә зур тагын бер өммәтне күрсәтерләр һәм ул (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) тагын: "Шулмы инде минем өммәтем?" - дип сорар. Җәбраил (аңа Аллаһның сәламе булса иде): "Әйе, бу синең өммәтең", - дияр. Шуннан соң Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде): "Мин сезнең белән горурланам", - дияр. Бу хәдис безне абортлар ясатмаска, күбрәк балалар тудырырга өнди. Чөнки ислам буйдак тормышны кире кага, никахта, гаилә белән яшәргә чакыра. Хәдистә болай дип тапшырыла: "(Мөмкинлекләре булып та) өйләнмәгән ир-атларга һәм (мөмкинлекләре булып та) кияүгә чыкмаган хатын-кызларга Аллаһның ләгънәте төшәр" (Әбу Давыдның Сөннәнендә китерелә). Әгәр дә зарурлык булса (мәсәлән, хатыныңның сәламәтлегенең начарлыгы яки игътибарга лаек башка сәбәпләр), шәригать йөккә узудан саклану чаралары (презервативлар, спиральләр һ.б.) кулланырга рөхсәт итә, ләкин бу - кешенең матди хәленә сылтап йөккә узудан саклануына кагылмый. Сүзләребезнең хаклыгын дәлилләү өчен өченче тәкъва хәлифә Госман бине Гаффанның сүзләрен китерик: "Без газелне куллана идек (ягъни йөклелектән саклана идек) һәм (аны тыеп) безгә Коръән иңдерелде".

Әгәр дә хатын-кыз авырга узгач, абортта зарурлык бар икән, әгәр дә йөклелек дүрт айдан да озаграк бармаган икән, аборт ясатырга була. Бу турыда "Раддел-Мохтар"да (2 т., 411 нче бит) һәм "Фәтхел-Кадыйр"-да (2 т., 495 нче бит) китерелә. Йөклелеккә дүрт айдан да артык вакыт үтсә, аборт ясау катгый тыела, чөнки бу вакытта аборт ясау шәригать буенча кеше үтерү булып исәпләнә (Бине Габидин, "Раддел-Мохтар", 5 т., 410 нче бит, "Фәтхел-Кадыйр", 4 т., 153 нче бит).

Шуңа күрә дә Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) әйткән: "Сөя торган һәм бала таба ала торган хатын-кызларга өйләнегез".

# ИСЕМЕҢ МАТУР, КЕМНӘР КУЙГАН?

Дөнья булгач, кемнәрдер туа, кемнәрдер үлә. "Үлгәннәрнең каберен бел, исәннәрнең кадерен бел", - дип бик дөрес әйткәннәр. Ә менә бала дөньяга аяк баскач, аның турында нәрсәләр белергә соң? Ата-ана үз өстендәге бурычларын, баланың хак-хокукларын белергә тиеш. Әгәр дә ата-ана үз өстендәге бурычларын вакытында үтәп барыр булса, бала тәрбияле булып үсәчәк һәм ул, иншә Алла, динебезгә дә, милләтебезгә дә, шулай ук сөекле ватаныбызга да файдалы кешеләрдән булачак.

Бала тугач аңа исем кушу ата-ананың иң беренче вазыйфаларыннан санала. Әмма балага кайбер исемнәрне кушарга ярамый. Моннан без исемнәрнең бер генә төрле түгел икәнлеген аңлыйбыз. Ислам галимнәре исемнәрне өч олы төркемгә бүләләр. Беренчесе – хәләл исемнәр, икенчесе – хәрам исемнәр, өченчесе мәкрүһ исемнәр. (Газетабызның киләсе санында бу төркемнәрнең һәркайсына аерым-аерым тукталырбыз.- **ред.**)

***(Гомәр Саттар-Мулилленең "Исемең матур, кемнәр куйган?" китабыннан)***

***ИР-АТ ИСЕМНӘРЕ***

Абай (борынгы төрки-татар исеме) - абый, өлкән ир туган мәгънәсенә ия.

Агиш (бор.төр.-т) - ак иш (дус, тиң).

Азамат (гарәпчә) - рыцарь, баһадир, кыю, батыр.

Азат (фарсыча) - хөр, ирекле

Айбулат (төр.-т.) - ай кебек чибәр, булат корыч кебек нык.

Айбүләк (бор. төр.-т.; йола исеме) - ай кебек чибәр, күркәм бүләк.

Айваз (ф.) - 1. Өй хезмәтчесе. 2.Якты ай, тулы ай. 3.Алмаш.

Айгиз (т.-ф.; неологизм) - айны гиз, айга мен.

Айгизәр (т.-ф.; неол.) - айны гизәр, айга менәр.

Айдар (төр.-т.) - ай сыйфатлы, маңгаенда ай йөртүче, дәрәҗәле.

Айдархан (төр.-т.) - Айдар + хан.

Айзат (т.-г.; неол.) - ай кебек күркәм зат.

Айкын (бор.төр.-т.) - ачык, анык, билгеле, җитез.

Айморза (төр.-т.-г.- ф.) - ай + морза.

Айназар (төр.-т.-г.) - ай + Назар. Ай кебек якты, нурлы карашлы.

Айнур (т.-г.; неол.)- ай нуры.

Айрат (бор.монг. яки г.) - монголча хайрат (кадерле, сөекле), гарәпчә хайрат (искиткеч).

Айсаф (төр.-т.-г.) - саф. ачык ай.

Айтимер (бол.-т.; й.ис.) - ай кебек саф һәм таза, нык тимер.

***ХАТЫН-КЫЗ ИСЕМНӘРЕ***

Абруй (ф.) - йөз суы, йөз аклыгы.

Адилә (г.) - гадел, тугрылыклы, намуслы.

Айбану (төр.-т.-ф.) - ай кебек бикә.

Айбикә (бол.-т.) - ай кебек бикә, риваятьтә ай кызы, Зөһрә кыз.

Айгөл (т.-ф.; неол.) - ай һәм гөл сыйфатлы; ай гөле.

Айзадә (төр.-т.-ф.) - ай кебек кыз бала.

Айзилә (төр.-т.-г.) - ай кебек пакь, керсез, саф.

Айзирәк (т.-ф.; неол.) - зирәклегенә сокланырлык кыз бала.

Айзифа (т.-ф.) - ай кебек сылу, зифа, чибәр.

Аййолдыз (т.; неол.) - ай һәм йолдыз кебек.

Айназа (т.-ф.; неол.) - ай кебек назлы.

Айниса (т.-г.) - ай кебек хатын.



# ҮПКӘЛӘШТӘН БУЛМАСЫН!

Әййүбдән (Аллаһ аннан разый булса иде) Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) шундый сүзләрен тапшыралар:

"Мөэмин кешегә үзенең мөселман кардәше белән очрашкан вакытта, аннан борылып китеп, өч көннән дә артык аралашмыйча тору (ягъни, өч көннән дә артык аңа үпкә тоту) тиеш түгел. Алар арасында кем беренче булып икенчесенә сәлам бирә, шунысы яхшырактыр" (Бохари, Мөслим).

Әбу Һөрайрадан (Аллаһ аннан разый булса иде) Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) шундый сүзләрен тапшыралар: "Мөэмин икенче бер мөселманга өч көннән дә артык үпкә тотарга тиеш түгел. Өч көн үткәннән соң, ул аңа барып сәлам бирсен. Әгәр дә икенчесе аның сәламенә җавап бирсә - савабы икесенә дә булыр, әгәр дә инде ул сәламгә җавап бирмәсә - гөнаһы үзендә калыр".

Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) әйткән: "Әгәр дә кем дә булса өч көннән дә артык үпкә саклап, (шул үпкәсе белән) вафат булса, ул тәмугка эләгер" (Әбу Давыд, Әдәб, 55).

**Islam-Today**

# АХЫРЗАМАНДА...

**Ахырзаманда, Кыямәт көне алдыннан, кешелек җәмгыятендә бар дөньяда төрле җәнҗаллар кубар. Гаҗәп тә түгел! Аллаһының Рәсүле Мөхәммәд әл-Мостафаның (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде): "Кыямәт көне алдыннан җиргә утыз ялган пәйгамбәр килер", - дип әйтүе билгеле. Ул ялган пәйгамбәрләрнең аңнары һәм күңелләре Иблиснеке кебек булыр. Бу ялганчылар, Иблискә ярдәмдә булган "пәйгамбәрләрнең" һәрберсе дә гадәттән тыш сәләтләр күрсәтер, ялган тәгълиматлар, идеологияләр кармагына эләккән керсез җаннарны үз байраклары астына җыяр.**



Исламның нигезләрен җимерми торып, мөселманнарны идеологик колларга әйләндереп тә, җиңеп тә булмый. Шуңа да мөселманнар тормышында һәм аларның кылган гамәлләрендә таркаулык кертү өчен әзерләнгән төрле лаборатория агымнары, төркемнәре бер-бер артлы пәйда булалар. Барлык төркемнәр, агымнар да бер төрле фикер нигезендә оешалар, ныгыйлар һәм һәрнәрсәне шул фикергә хезмәт иттерергә тырышып карыйлар: аларның берләре исламдагы "бидгатьләр" белән көрәшә, икенчеләре - "ширек чагылышлары" белән, ә өченчеләре исә "бөтендөнья хәлифәте" төзү белән мәшгуль.

Шулар арасындагы бер сәер, шикле, шөбһәле бер фирка менә инде җиде дистә ел буе мөселман өммәтен үзара болгатып, аларны куралмаучанлык, дошманлык упкынына ташларга маташа. Сүз "Хизбүт-тәхрир әл-ислами" ("Исламны азат итү фиркасе") дип аталып йөрүчеләр турында бара. Алар үзләрен

> ***Бөтендөнья хәлифәтен төзү турындагы шигарьләр - чып-чын ялган! Бу ялганның максаты - мөселманнарны урамнарга чыгару, хаос һәм фетнә орлыклары чәчү, илнең закон тыңлаучан мөселман халкын хокук бозучы чараларга җәлеп итү.***

хәлифәт, ягъни бөтендөнья ислам дәүләте тарафдарлары дип саныйлар. Бу төркемне оештыручылар үзләренә әлеге исемне юкка гына алмаганнар инде.

"Хизбүт-тәхрир әл-ислами" - мөселман өммәте вәкилләренең аңнарына йогынты ясау, миләренә тиешенчә тәэсир итү өчен Британия империясе лабораторияләрендә ясалган күпсанлы сәяси коралларның берсе. Шуңа күрә Британия мәнфәгатьләренә хезмәт итәргә тиешлеге – табигый хәл. Бу сәер фирка соңгы елларда Татарстан, Башкортстан җөмһүриятләрендә мөселманнарны адаштыру-саташтыру юллары, ысуллары өстендә бик ныклап эшли.

Татарстанда, Башкортстанда, илебезнең башка регионнарында ислам дөньясының башка илләре белән чагыштырган вакытта мөселманнарның хәле күпкә яхшы. Яңа төзелгән меңнәрчә мәчетләр, эшләп торучы ислам уку йортлары, белемне дәвам итәр өчен чит илгә чыгу, хаҗ кылу, шәригать кануннары буенча бизнес алып бару мөмкинлекләренең булуы турында әйтеп торырга да кирәкми. Болар болай да билгеле фактлар, табигый нәрсә. Россия дәүләтенең хокук саклау табигате дөньяви характерда булуына карамастан, күп кенә өлкәләренең тәртипләре мөселман шәригате кануннарын хәтерләтә. Мәсәлән, Гаилә кодексына күз салыгыз.

Бер карасаң, тыныч кына матур итеп яшә, хезмәт ит, гыйбадәт кыл, чынга ашмастай әйберләр белән хыялланып ятма кебек. Ләкин тыныч кына яшәү "исламны азат итү фиркасе" дип аталып йөрүчеләрнең планнарына керми булса кирәк. Менә инде соңгы берничә ел буе, асылы белән сектант булган бу төркем Татарстан, Башкортстан, Идел буе, Урал һәм Себер регионнарында, зур шәһәрләрдә, шәһәрчекләрдә, хәтта авылларда да мөселманнар арасында фетнә чыгарырга тырыша. Уйлап чыгарылган төрле сылтаулар белән әлеге төркем вәкилләре мөселман дин әһелләре, галимнәре һәм гади мөселманнар, имамнар һәм мәхәллә халкы арасында төрле каршылыклар, таркалышлар кертергә тырыша. Мәчетләрдә җомга намазларының тәртибе бозыла, мәхәллә халкы арасында "имешмимешләр" таратыла, хәзрәтләребезнең абруен юк итәргә көч түгелә, мәчет җирен ялган фикерләр тарату буенча сәяси мөнбәргә әйләндерергә тырышыла.

Бу төркем активистлары ялган һәм мәкерле алдау юллары белән үзләренең хокуксыз эшчәнлекләренә Татарстан, Мәскәү, Санкт-Петербург һ.б. регион һәм шәһәрләрнең мөселманнарын гына түгел, ә Россия территориясендә булган чит ил гражданнарын да җәлеп итәргә тырышалар. "Исламны азат итү фиркасе"нең соңгы "акцияләре", гомумән, үзләренең мәкер һәм астыртынлыгы белән таң калдыра. Алар үзләренең Иблис яраткан бу оешмаларына балигъ булмаганнар һәм пенсия яшендәге хатын-кызларны тарталар.

"Хизбүт-тәхрир әл-ислами"-ның Россия мөселманнарын кемнән азат итәргә тырышулары хәзер ачыкланып бара инде. Сез дә төшенеп алгансыздыр дип уйлыйм, мөхтәрәм җәмәгать. Асылда сүз башка берни турында да түгел, ә Россияне ... исламнан азат итү турында бара! "Хизбүт-тәхрир әл-ислами" үзенең шайтан уеннары белән Россиядә исламны юк итәргә тырыша дигән сүз! Закон кысаларыннан чыгып, җәмгыятьтә шикләнүчәнлек, үзара ышанмаучылык шартларын тудырып, халыкның төрле катламнарын хокукка каршы эшчәнлеккә җәлеп итеп, "Хизбүт-тәхрир әл-ислами" җәмгыятьтә көч куллану һәм кешеләрнең аңнарында төрле буталчыклыклар китереп чыгарырга тырыша, төрле дин, милләт ияләрен бер-берсенә дошман ясарга уйлый.

"Хизбүт-тәхрир әл-ислами" төрле фетнә, провокацион вакыйгалар барлыкка китерүе нәтиҗәсендә илдә көнкүреш исламофобиясе килеп чыгуга һәм булуга җаваплы.

Әлбәттә, бу фетнәче, провокацион төркемгә нигез салучылар, мөселман шәригатен яхшы беләләр һәм төрле мөселман халыкларының мантыйк вә әхлак үзенчәлекләрен дә яхшы өйрәнгәннәр. Ләкин алар бер нәрсәне исәпкә алмаганнар - безнең хөрмәтле Пәйгамбәребез Мөхәммәд әл-Мостафа (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде) мөселманнарны болай өйрәткән: "Мөселман өммәте бервакытта да ялгышу юлында берләшә алмаячак".

Бүгенге көндә без, мөселманнар, бөтен халык ишетерлек итеп шуны әйтергә, ачыкларга тиешбез:

- хак мөселманнарның марыкый (еретик) "Хизбүт-тәхрир әл-ислами" сектасына бер катнашлары да юк;
- хак мөселманнар тәүбә итмәгән һәм бу сектаны ташлап китмәгән кешеләрне үзләренең сафлары исемлегеннән чыгарып ташлаячаклар;
- хак мөселманнар, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһ алдында ихлас тәүбә итеп, бу секта белән араларын өзеп, әһле-сөннәт вәл җәмәгать сафларына кайтучыларның барысын да кабул итәргә әзерләр.

Гарәп хәрефен танымаган ялган "имамнар" алданган демонстрантлар кулына асты өскә әйләндерелгән шәһадәт тоттырдылар, ә хәзер исә инде алар алданган мөселманнарның аңнарын, күңелләрен астын өскә әйләндерергә телиләр.

"Хизбүт-тәхрир әл-ислами" сафларында булу - Иблис коткысына бирелү, ул шайтан өчен генә яхшы.

"Хизбүт-тәхрир әл-ислами" юлы - өммәтне таркатучылар юлы.

"Хизбүт-тәхрир әл-ислами" сафларында булу - тәмуг утына туры юл.

Ислам ул, гомумән әйткәндә, яхшы киңәш һәм нәсыйхәт. Шуңа күрә, без "Хизбүт-тәхрир әл-ислами"ның ялган идеологиясе белән алданган бар кешеләргә дә аннан баш тартырга һәм җаннарын коткарып калу өчен туры юлга кире кайтырга киңәш бирәбез һәм чакырабыз.

Асты өскә әйләндерелгән шәһадәтле байраклар артыннан киткән бар кешеләрне дә наданлык һәм саташу йокысыннан уянырга чакырабыз!

Бөтендөнья хәлифәтен төзү турындагы шигарьләр - чып-чын ялган! Бу ялганның максаты - мөселманнарны урамнарга чыгару, хаос һәм фетнә орлыклары чәчү, илнең закон тыңлаучан мөселман халкын хокук бозучы чараларга җәлеп итү.

Аллаһы Тәгалә, Раббыбыз, безне Яратучы, Халикъ Үзенең Каләм шәрифендә: "Ий, мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Коръән хөкемнәренә ныклап ябышыгыз! Аннары Коръән хөкемнәреннән һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез! Янә Аллаһ сезгә биргән нигъмәтләрен күңелегездә саклагыз, бит мөселман булмас борын, бер-берегезгә дошман идегез. Аллаһ ислам дине белән күңелегезгә дуслык, әлфәт-мәхәббәтен салды да, бер-берегезгә дин кардәше булып әверелдегез. Сез җәһәннәм ярының читенә килгән идегез, җимерелеп төшәргә генә калган идегез, Аллаһ рәхмәт кылып, җәһәннәмгә төшүдән сезне ислам дине белән коткарды. Әнә шулай Аллаһ сезгә аятьләрен ачык бәян итәр, шаять дөрес аңлап, дөрес гамәл кылып туры юлга күнелерсез!" - дип аңлаткан да, кисәткән дә, күңелләргә өмет тә салган ("Әли-Гыймран" сүрәсе, 103 нче аять).

Аллаһның бу сүзләрен искә алыгыз һәм җаннарыгызны тәмуг утыннан саклагыз!

Чит илләрдә урнашкан "Хизбүт-тәхрир әл-ислами" фиркасенең башлыкларына да бирә торган киңәшебез бар: исемегезне җисемегезгә туры китерергә кирәк! Төркемегез ялган исем йөртә, янәсе, "Исламны азат итү фиркасе", инде вакыт җитте, исемегезне "Хизбүт-тәхрир минәл-ислам" яки "Исламнан азат итү фиркасе" дигәнгә алыштырыгыз. Шул очракта исемегез җисемегезгә туры килер!

**Фәрид хәзрәт СӘЛМӘН**

# “ХУЗУР”НЫҢ КИБЕТЛӘРЕ – БАЙ, БӘЯЛӘРЕ – КУЛАЙ

Россия ислам институты бинасында “Хузур” нәшрият йортының тагын бер кибете ачылды. Бу институт җитәкчелеге тәкъдиме белән, студентларның мәнфәгатен кайгырту йөзеннән тормышка ашырылды. Нәшриятның тагын бер кибете Татарстан Җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте бинасында уңышлы гына эшләп килә. Мөфтиякә килгән кеше биредән китаплар да сатып алып китә.

“Хузур”ның кибет киштәләре көннән-көн яңа китаплар белән байый бара. Нәшрият йортында басылып чыккан китаплар киштәсенә шушы көннәрдә генә “Шура” журналының 1, 2 нче саннары, Таҗетдин Ялчыголның “Рисаләи Газизә” китабы менеп урнашты. Тиздән Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның рус һәм татар телләрендә нәшер ителгән “Җеннәр турында”гы китабы, Фәрид хәзрәт Сәлмәннең “Аятел көрси” (фазыйләтләре белән) китабы һәм Диния нәзарәте тарафыннан чыгарылган 2015 нче елга мөселман календаре – “Дини тәкъвим” сатуга куелачак.

Болардан тыш кибетләрдә башка нәшриятларда чыккан, Диния нәзарәтенең эксперт комиссиясе тарафыннан тикшерелгән китаплар, шәмаилләр, намазлыклар, кәләпүшләр һәм башка гыйбадәт кирәк-яраклары сатыла.

“Хузур” нәшрият йорты хәзер мөхтәсибәтләр белән дә тыгыз хезмәттәшлек итә. Әлеге нәшриятта чыккан китапларны район мөхтәсибәтләрендә, мәчетләрдә дә сатып алырга була. Ә Россиянең башка төбәкләрендә яшәүчеләрнең “Хузур” сайтында сайлаган китапларны почта аша заказ белән соратып алу мөмкинлеге дә бар.


**“Хузур” Нәшрият йортының сайты - huzur.ru; Казандагы кибетләре адреслары: Лобачевский урамы, 6 нчы йорт һәм Газовая урамы, 19 нчы йорт; заказ бирү өчен телефоннар: (8843)2-02-07-74, 8 96 55 96 55 37.**




# ТАТЛЫ ҖИМЕШЕМ

Үзе татлы, үзе туклыклы, үзе шифалы... Бу ни булыр икән, дисезме? Сүз Коръәни-Кәримдә 20 урында, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам сөннәтендә күп тапкырлар искә алынган хөрмә җимеше турында бара.


Изге Коръәннең “Мәрьям” сүрәсендә болай диелә: “...хөрмә агачының кәүсәсеннән тотып үзеңә таба селкет, төшерер сиңа яңа өлгергән хөрмә җимешен. Ул хөрмәне аша вә чишмә суын эч...” (25-26 нчы аятьләр). Һәм Гайсә галәйһиссәламгә йөкле Мәрьям-ана шул татлы җимешләрдән авыз иткән. Пәйгамбәребез (с.г.в.): “Өйлә-рендә хөрмә булмаган кешеләр - ачлар”, - дигән. Ул үзе аларны яшел килеш тә, өлгергәнен дә, май яки ипи белән дә, карбыз, кавын, кыяр белән дә ашарга яраткан.




Хөрмә җимеше кеше организмы өчен файдалы матдәләргә бай, ул күп төрле авырулардан дәвалау үзлегенә ия.

Аның составында сахароза һәм глюкоза, А, А1, С, В1, В2, В6 витаминнары, 23 төрле аминокислота, 15 төрле тозлар һәм минераллар бар.

***Хөрмә җимешен Казан шәһәре, Уң Болак урамы, 47 нче йорт адресы (тел. +7 (987) 296 09 50) буенча сатып алырга була.***




# РӘҖӘП - АЛЛАҺ АЕ

Бу айда булган вакыйгалар:

1 нче көнендә дөньяны су баса башлый. Нух пәйгамбәрнең өендә мич төбеннән су саркып чыга; 4 нче көне - Рәгаиб кичәсе - Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) әтисе Габдуллаһ белән әнисе Әминәнең никахлашкан көннәре; 5 нче көне - Рәгаиб кичәсе көне; 26 нчы көне - Мигъраҗ кичәсе; 27 нче көне - Мигъраҗ кичәсе көне.

Пәйгамбәребез (с.г.в.): “Рәҗәп - Аллаһның ае, шәгъбан - минем аем, ә рамазан - өммәтемнең ае. Бу айда чын күңелдән тәүбә итүчеләргә Аллаһы Тәгаләнең мәгърифәте иңә, бу айда кан түгү, сугышлар тыелган, бу айда Аллаһы Тәгалә бөтен пәйгамбәрләрнең догаларын кабул кылган һәм күп кенә әүлияләрне (изгеләрне) дошманнарының кулыннан коткарган”, - дигән.

Рәҗәп - Аллаһы Тәгалә кан коюларны һәм низагларны тыйган дүрт айның берсе.

Дин вә Мәгыйшәт

**Гамәлгә куючы: Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте** *(420111 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27)* .
**Нәшир: “Хузур” нәшрият йорты** *(420111 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 10в).*

**Апрель саны, № 4 (225)**

**Баш мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ
**Мөхәррир:** Нәүбәһар КӘБИРОВА
**Дизайнер:** Фәнис Мотыйгуллин
**Корректор:** Айгөл КРОХИНА
Газета логотибы **хәттат** Рамил НАСЫЙБУЛЛОВ тарафыннан эшләнде

**Редакция советы:**
*Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе **Камил СӘМИГУЛЛИН**;*
*“Хузур” нәшрият йорты директоры **Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;*
*Татарстан мөфтие урынбасары **Нияз САБИРОВ**;*
*Татарстанның баш казые **Җәлил ФАЗЛЫЕВ**;*
*Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы рәисе **Габдулла ӘДҺӘМОВ**.*

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета “Татмедиа” ААҖ филиалы – “Идел-Пресс” полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).
Заказ № 09609
**Тираж: 10 мең данә**
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя – 6 сум.
График буенча бу санга **21 нче апрель көнне 18.00 сәгатьтә** кул куелырга тиеш иде. **Кул куелды: 18.00 сәгатьтә.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
**Электрон адрес: niyaz-kazan@yandex.ru**
**Телефон:** +7 (843) 267-29-67.

**Язылу индексы: 16046**
**Татарстанның һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин.**